АШЛЫ ЭШ

Базарлы Матакта яшәүче балта остасын чит илдә дә беләләр

> 15

ИКЕ ТӘГӘРМӘЧ

Татарстанда велосипедка утыручылар арта

> 16

ФӘРИТ БИКЧӘНТӘЕВ:

«Тамашачыны яратырга кирәкми, аны хөрмәт итәргә кирәк»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 69 (28842) | Җомга | 20 май | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

visit-tatarstan.com

ҮТКӘННӘН – КИЛӘЧӘККӘ

ТАТАРСТАНДА ИДЕЛ БУЕ БОЛГАР ДӘҮЛӘТЕНДӘ ИСЛАМ ДИНЕН КАБУЛ ИТҮНЕҢ 1100 ЕЛЛЫГЫН БӘЙРӘМ ИТӘЛӘР

Бу көннәрдә Татарстан Россия белән Ислам дөньясын тагын да якынайткан урынга әверелде. Казанга дин әһелләре белән бергә икътисадчылар һәм сәясәтчеләр дә җыелды. Җыен һәм очрашулар бәйрәм чаралары белән генә чикләнми. Төрле илләрдән килгән белгечләр киләчәк турында фикер алыша. Шулай итеп, моннан 11 гасыр элек булган тарихи вакыйга аерым бер милләтнең яшәү рәвешенә генә йогынты ясап калмыйча, бүген халыклар һәм дәүләтләр арасындагы мөнәсәбәтләрдә дә чагылыш таба.

> 6–7

Ишетми калмагыз

Россия Президенты Владимир Путин киләсе атнада Дәүләт Советының социаль сәясәт мәсьәләләренә багышланган утырышын үткәрергә җыена. Анда социаль пособиеләрне, башка түләүләрне арттыру турында карар кабул ителәчәк. Бу хакта дәүләт башлыгы ярдәмчесе Максим Орешкин белдерде, дип хәбәр итә «РИА Новости». Исегезгә төшерәбез: Владимир Путин апрель ахырында парламентка пенсияләр һәм барлык социаль пособиеләрне, шулай ук бюджет өлкәсендә эшләүчеләрнең хезмәт хакын арттыруны карарга кушты. Моңа кадәр социаль пенсияләр 8,6 процентка арттырылды инде. Бу 4 миллион кешегә кагылды. Гадәти пенсионерларга карата да шундый ук карар кабул ителде.

Киләсе елда Татарстанда бәрәңге һәм яшелчә җирләрен киңәйтү өчен авыл хуҗалыгы җитештерүчеләренә ярдәм чаралары артачак. Татарстан авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары Ришат Хәбипов әйтүенчә, хуҗалыкларга гына түгел, кешеләрнең бакчаларына да кагыла бу. «Авылда яшәүчеләрнең күбесе үз вакытында бәрәңге җирләрен нык киметте», – дигән ул.
Министр урынбасары сүзләренә караганда, шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә республика бюджетыннан һәр ел саен 500 миллион сум чамасы бирелә. Шул исәптән сыер асраурга – 350 миллион сум. «Хәзерге вакытта Татарстан Президенты кушуы буенча авылда яшәүчеләрнең эшмәкәрлек активлыгын арттыруга багышланган зона семинар-киңәшмәләре уза. Аларда халыкның мөшкүлләрен саклау төп мәсьәлә буларак карала. Әлеге чаралар сала халкына 300 мең баш терлек, шул исәптән 100 мең баш сыерны саклап калу мөмкинлеге бирде», – дигән Ришат Хәбипов.

Россиядә бала карау буенча пособиенең иң зур күләме 2025 елга 57,4 мең сум тәшкил итәчәк. Бу хакта ТАСС Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы мәгълүматларына таянып хәбәр итә. Моннан тыш йөклелек һәм бала тудыру буенча пособиенең максималь күләме 660,9 мең сумга җитәчәк.
1 майдан 8-17 яшьлек балалар үстерүче гаиләләр өчен яңа айлык пособие түләнелә башлады. Татарстанда ул 79380 балага юллана.

Ял көннәрендә Татарстанда яңгырлы, суык һава көтелә. Кайбер районнарда карлы яңгыр явачак. Гидрометеоүзәктән хәбәр ителгәнчә, төньяк-көнбатыштан үтеп кергән Арктика һавасы агымы көннәрнең җылынуына ирек бирми. Төнге сәгатьләрдә һава температурасы 0...+5 градуска кадәр төшәчәк, урыны белән кырау көтелә. Көндез +7...+13 градус чамасы булачак.
Киләсе атна башында да яңгыр көтелә. Көндез 23 майда термометрның терекөмеш баганасы +9...+14, 24 майда +11...+16 градус күрсәтәчәк. Төнлә 0...+6 градус. Урыны белән кырау төшәргә мөмкин.
Быел майның суык килүе сәбәпле, кыр һәм бакча эшләре кимендә 2 атнага соңара.

Ил өчен мөһим вакыйга

Россия Президенты Владимир Путин Болгар дәүләтендә ислам дине кабул итүнең 1100 еллыгына багышланган чарада катнашучыларга һәм аны оештыручыларга сәламләү юллаган.

«Кадерле дуслар! Сезне чын күңелдән Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулу – дөнья мөселман өммәте өчен һәм, әлбәттә, бөтен илебез өчен мөһим вакыйга белән котлыйм.

Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итү илебез тарихында иң әһәмиятле вакыйгаларның берсенә әйләнеп, илнең күпконфессияле дәүләт буларак формалашуына йогынты ясый, Россиянең күпмилләтле бердәм халкын булдыруга мөһим өлеш кертә. Мөселманнар йөзләрчә еллар дәвамында илебезне үстерүгә үзләреннән саллы өлеш кертеп килә. Аларның төрле өлкәләрдәге казанышлары – гаять бай тарихи, фәнни, мәдәни һәм рухи мирасыбызның аерылгысыз өлеше.

Россия мөселманнарының бүгенге буыны ата-бабаларының традицияләрен һәм гореф-гадәтләрен кадерләп саклый, аларның Ватанга намуслы хезмәт итү васыятенә, ватанпәрвәрлек һәм гаделлек төшенчәләренә тугры булып кала. Мөселман хәрбиләр Украинада махсус хәрби операция үткәрү барышында ныклык, фидакарьлек һәм батырлык үрнәкләре күрсәтә.

Россия мөселманнары илнең халыкара элемтәләрен киңәйтүдә актив катнаша. Моны бүгенге чаралар, барыннан да элек, «Россия – Ислам дөньясы: KazanSummit 2022» XIII халыкара икътисади саммиты һәм «Россия – Ислам дөньясы» стратегик караш төркеменең чираттагы утырышы раслый.

Ике яклы хезмәттәшлек буенча, шулай ук Ислам хезмәттәшлеге оешмасы белән хезмәттәшлек кысасында мөселман илләре белән дустанә мөнәсәбәтләрне ныгытуга зур әһәмият бирәбез. Төбәк һәм глобаль дәрәҗәдәге күп кенә мөһим проблемаларны бергәләшеп хәл итәргә тырышабыз, халыкара мөнәсәбәтләрдә куркыту, кысу, сәяси һәм икътисади басымны куллануга бергәләшеп каршы чыгабыз. Алга таба да сәүдә-икътисади, фәнни-техник, гуманитар өлкәләрдә h.б. үзара файдалы хезмәттәшлекне үстерүгә исәп тотабыз.

Чаралар кысасындагы очрашуларның үзара фикер алышуга, шулай ук перспективалы башлангычларга этәргеч бирүгә ярдәм итәчәгенә ышанам», – дигән Владимир Путин.

Халыкара икътисади саммитта катнашучылар һәм оештыручыларга Россия Премьер-министры Михаил Мишустин һәм тышкы эшләр министры Сергей Лавров та сәлам юллаган. Ил Хөкүмәте Рәисе саммитның Россия белән Ислам дөньясы арасындагы эшлекле элемтәләрне, безнең илләр һәм халыклар арасында аңлашуны ныгытуга ярдәм итәсенә ышаныч белдергән. Ә Сергей Лавров фикеренчә, Казанда уза торган чаралар Россиянең Ислам дөньясы белән бүгенге мөнәсәбәтләренә һәм аның киләчәгенә тарихи күзлектән карарга мөмкинлек бирә.

РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВ:

«ХӘЛӘЛ – ЯШӘҮ РӘВЕШЕ ҺӘМ ТУЛЫ БЕР ИНДУСТРИЯ»

tatarstan.ru

«KazanSummit» турында кызыклы мәгълүмат

✓ Быел әлеге чара өч көнгә сузылачак. Билгеле булганча, узган елларда саммит җәен һәм ике көн генә була иде.
✓ Быел саммит 59 илдән һәм Россиянең 42 төбәгеннән 5 мең катнашучыны бер мәйданга җыйды. Кунакларның күпчелеге Төркия, Гарәп Әмирлекләре һәм Ираннан килде.
✓ Быел «Russia Halal Expo» күргәзмәсенең мәйданы, узган ел белән чагыштырганда, ике тапкыр артып, 10 мең квадрат метрга кадәр җитте. Анда җиде илдән 140 экспонат тәкъдим ителә. Күргәзмәгә керү иркеле.
✓ «Казансаммит» кысасында дөньякүләм масштабтагы чара: «World Halal Day» (Бөтендөнья хәләл көне) уза. Ул Җир шарының төрле илләрендә 2014 елдан бирле үткәрелә.

Өч көн Казан хәләл бизнес өлкәсе тирәсендә кайнаячак. Кичә башкалада «Россия – Ислам дөньясы: KazanSummit 2022» XIII халыкара икътисади саммиты һәм аның кысасында «Russia Halal Expo» халыкара күргәзмә ачылды. Инде газетаның узган саннарында искәрткәнебезчә, быел әлеге чара тагын да зуррак масштабларда уза. Чөнки ул Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен рәсми кабул итүнең 1100 еллыгына багышланган чаралар белән үрелеп бара.

– «KazanSummit» – безнең илдә Россия төбәкләре һәм Ислам хезмәттәшлеге оешмасы илләренең икътисади бәйләнеше өчен бердәнбер һәм төп мәйдан, – диде Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов чараны ачу тантанасында. – Ул үзен яңа элемтәләр булдыру һәм безнең илнең икътисади мөмкинлекләрен һәм инвестиция потенциалын күрсәтү өчен уңышлы бизнес-платформа булуын күрсәтте.

Шулай ук ул хәләл күргәзмәнең Россиядәге хәләл индустриясе популярлаштыруга, икътисадның хәләл мөмкинлекләрен күрсәтүгә, продукцияне сатып алучыларга һәм партнерларга тәкъдим итүгә юнәлгән булуын әйтте. Гомумән алганда, Рөстәм Миңнеханов быелгы программаның гаять бай булуын ассызыклады. Партнерлык финанслары, медицина, спорт, креатив индустрия, экспортны үстерү һәм башка юнәлешләр буенча фикер алышулар булачагын әйтте. Чараның буеннан-буена кызыл җеп булып сузылып килә торган төп тема исә – бердәм куллану икътисады һәм хәләл иминлек.

Рәсми ачылыштан соң Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов күргәзмәне карады. Бирегә, елдагыча, хәләл ризыклар, машина төзелеше, сәнәгать оешмалары эшләнмәләре, матурлык һәм мода индустриясе тәкъдим ителгән иде. Президент һәм чит ил кунаклары узган гасыр үрнәкләре буенча яңадан торгызылган кабатланмас Коръән китабы, Болгар юртасы, музыкантлар, «Татнефть» компаниясе стенды янында тукталып, аларга аерым игътибар күрсәттеләр.

Күргәзмә белән танышып чыккач, рәсми делегация пленар утырышта катнашты. Россиянең икътисади үсеш министры Максим Решетников саммит кунакларын сәламләп, «KazanSummit»ның Россия төбәкләренең ислам илләре белән бәйләнеше өчен мөһим мәйдан булуын белдерде.

– Биредә иң актуаль мәсьәләләр күтәрелә, ә иң мөһиме – позицияләр якынаю һәм уртак проектларны тормышка ашыру буенча карарлар кабул ителә. Мондый килешүләр һәм партнерлыкны үстерү хәзер бик кирәк, – диде ул.

Татарстан Россия һәм ислам илләре арасындагы мөнәсәбәтләрне ныгытуда зур роль уйный. Әлеге фикерне Төрекмәнстанның элеккеге Президенты, хәзер Милли Генгешы Халк Мәсләхәте Рәисе Гурбангулы Бердымөхәммәдов әйтте.

– «Россия – Ислам дөньясы» халыкара икътисади форумын Казанда уздыру – ике арадагы дуслык һәм аңлашу мөнәсәбәтләре ныгынын ачык күрсәтекче. Монда Татарстан уникаль роль уйный. Республика икътисади, сәүдә, инвестицияләр, гуманитар өлкәләрдә халыкара дәүләти хезмәттәшлекне үстерүгә юнәлдерелгән күп проектларны башлап җибәрүче һәм күпер салучы булып тора, – дип билгеләп узды экс-Президент һәм соңгы вакытларда Татарстан белән Төрекмәнстан арасында аерым бер эшлекле мөнәсәбәтләр булдырылуын ассызыклады.

Пленар утырышта чыгыш ясаган Рөстәм Миңнеханов фикеренчә, хәләл индустрия үсешендә Россиянең мөмкинлекләре зур. Ул бүген ислам дөньясының халыкара сәясәттә, икътисадта һәм гуманитар бәйләнешләрдә үз кызыксынулары булган цивилизацияле берлек булуын әйтте.

– Билгеле, соңгы еллардагы һәм айлардагы глобаль үзгәрешләр ислам икътисадына тискәре йогынты ясамыйча калмады. Ләкин икътисади тормыш та үз хәленә кайта, хәләл куллану чыгымнары артыр дип фаразлана, – дип билгеләп узды Президент.

Рөстәм Миңнеханов фикеренчә, 20 миллионнан артык мөселман яшәгән территория хәләл индустриядә зур мөмкинлекләргә ия. Бу ризык кына түгел, туризм, медицина, мода, IT- технологияләр һәм башкалар.

– Бүген Татарстанда 100дән артык оешма хәләл продукция эшләп чыгара, аларның егермеләбе товарларын чит илгә чыгара. Илдә, гомумән, хәләл медицина һәм косметикага кызыксыну арта. Моннан тыш, безнең илдә Хәләл Френдли стандарты буенча кунакханә челтәрләренә һәм туроператорларга сертификация уздыручы оешмалар бар. Хәләл бүген – яшәү рәвеше һәм тулы бер индустрия, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Саммит кысасында шулай ук төрле мәйданчыкларда фикер алышулар, эшлекле очрашулар узды, килешүләр төзелде. Мәсәлән, SberTalk сессиясендә Рөстәм Миңнеханов Россия төбәкләрендә ислам банкингына ихтыяҗ булырга мөмкинлеген әйтте. Аның фикеренчә, законнарга тиешле үзгәрешләр кертеп, бу секторда гына махсус структура булдыру, шулай ук Россия субъектларында салым салуның һәм банк эшенең махсус режимын билгеләү белән эксперимент үткәрү – мөмкин хәл.

Зөһрә САДЫЙКОВА

ТАРИХКА СӘЯХӘТ

Тарихи вакыйга уңаеннан узучы чаралар Татарстан белән генә чикләнми. Россия Дәүләт Думасында Идел Болгарында ислам дине кабул ителүгә 1100 ел тулуга багышланган күргәзмә ачылды. Тантаналы чарада Россия Дәүләт Думасы Рәисе Вячеслав Володин белән Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та катнашты.

Күргәзмәдә Идел буе төбәгендә ислам үсешенең барлык чорлары чагылыш тапкан. Моннан тыш биредә сирәк архив документлары, кульязмалар, бизәнү әйберләре, милли киемнәр, Татарстанның Милли музее, Милли китапханә, Милли архив, Алабуга, Болгар һәм Биләр музей-тыюлыклары фондында сакланган башка экспонатлар белән дә танышырга мөмкин.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов әлеге чараны уздырырга мөмкинлек биргән өчен Дәүләт Думасы җитәкчелегенә рәхмәт әйтте. «Россия Президенты Владимир Путин карары нигезендә Идел Болгарында ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгы федераль дәрәҗәдә билгеләп үтелә. Оештыру комитетын Россия Премьер-министры урынбасары Марат Хөснуллин җитәкли. Бездә бик күп чаралар узачак. Узган ел без Казанның Изге Мәрьям ана иконасы соборын ачтык. Быел Җәмигъ мәчетенә нигез салачакбыз», – диде Президент.

Вячеслав Володин да, үз чиратында, Рөстәм Миңнехановка күргәзмә оештырган өчен рәхмәт сүзләре җиткерде. Дәүләт Думасы Рәисе күргәзмәнең ислам тарихы аша ил тарихын колачларга мөмкинлек бирүенә игътибар итте. «Ата-бабаларыбызның тормыш-көнкүрешен кадерләп тоту – безнең төп бурыч. Без бер-беребезнең диненә хөрмәт белән карыйбыз. Безгә моның кадерен белергә кирәк. Бу күргәзмә соңгысы булмас дип өметләнәм», – диде ул.

Татарстан тарафыннан оештырылган күргәзмәдә төрле партия вәкилләре дә катнашты. КПРФ партиясе җитәкчесе Геннадий Зюганов Татарстанның үсеш тәҗрибәсе башкаларга үрнәк булырлык дигән фикердә. «Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановка рәхмәт белдерәм. Сез иң болганчык елларда да һәйкәлләрне сүтмәдегез, урамнар исемен үзгәртмәдегез, Ленин музеен торгызырга ярдәм иттегез. Татарстан дин һәм татулыкның данлы традицияләрен дәвам иттерә», – диде ул.

ЛДПР фракциясе җитәкчесе урынбасары Ярослав Нилов исә мондый күргәзмәләрнең бер-берсенне яхшырак белергә мөмкинлек бирүен ассызыклады. «Гадел Россия» партиясе депутаты Александр Бабаков, Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителүгә 1100 ел тулуны билгеләп үтү – дәүләтчелекне формалаштыруда мөһим вакыйга, илнең төрле төбәкләрендәге мәдәният белән танышу өчен менә дигән мөмкинлек, дип бәяли.

«Новые люди» партиясе җитәкчесе Алексей Нечаев күргәзмә белән танышканнан соң республика үсешенә югары бәя бирде. «Күргәзмәне зур кызыксыну белән карадым. Татарстан үткәне белән горурланып кына калмый, бүген дә төбәк икътисадын үстерә. Безнең күптөрлелектә – зур көч», – диде ул, күргәзмәдә алган хис-кичерешләре белән уртаклашып.

«Бердәм Россия» партиясе җитәкчесе Владимир Васильев, Татарстанга килеп, еш кына тәҗрибә туплап кайтуы турында сөйләде. «Тарихка күз салу мөмкинлеге тудыруыгыз өчен рәхмәт. Минтимер Шәрипович алдында баш иям. Рөстәм Нургалиевичка рәхмәт белдерәсем килә», – диде ул.

КИМ ИТӘСЕ КИЛМИ

Яшәеш

«Балагыз авыру». Әлеге сүзләр тормышны икегә бүлә. Күп очракта таякның авыр башы әни кешегә төшә. Төбәк белән идарә итү үзәгенең проект офисы утырышында физик мөмкинлеге чикләнгән кешеләрне борчыган сорауларга җавап эзләделәр.

Казан шәһәр думасы депутаты, «Барысы да балалар өчен» хәйрия фондын оештыручы, үзе дә авыру бала үстерүче Далия Гайнанова, хатын-кызларга ярдәм кирәк, ди.

– Авыруларның төрлесе бар. Сабыена аутизм диагнозы куелган әнинең хәлен беркем дә аннан яхшырак аңламаячак. Үйлап карагыз әле: башта авырлы чагында аңа табиблар, сезнең балагызда ниндидер тайпылыш бар, дисә дә, аермачык үзенә бу авыру хакында аңлатучы юк. Аннары инде бала табу йортында ул тагын бер кат стресс кичерә, – ди Далия Гайнанова. – Өйгә килүче педиатр да, сырхауханәдәгесе дә кая барасын, бу авыру белән ничек яшисен әйтми. Ананың дөньяга күзе ачылып, баласын күтәреп, тернәкләндерү үзәгенә баргач, аны сүгеп ташлыйлар.

Далия ханым бу хакта озак сөйли ала. Аның фикеренчә, төрле авырулардан интегүче сабыйларның әти-әниләре өчен махсус сайт булдырырга кирәк. Нинди диагноз куелган, андыйларны кайда дәвалыйлар, тернәкләндерү үзәкләре бармы, нинди бакчага бирәсе, ничек укытасы... Боларның барысы турында да бер урында мәгълүмат тупланса, яхшы булыр иде, ди ул.

Балаңа нинди генә диагноз куелса да, аны кешедән ким итәсе килми. Казанда яшәүче Гөлшат Шаехова әнә шулай ди. Балаларына Даун синдромы диагнозы куелгач, аны ире ташлап китә. Өстәвенә ирнең әти-әнисе дә, безгә авыру онык кирәкми дип, килен белән арасын өзә. Ә Гөлшатның бик тә баласын тормышка әзерлисе, башка сабыйлар белән бергә бакчага йөртәсе, мәктәптә укытасы килә.

Татарстанның хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Эльмира Зарипова әйтүенчә, «Иртә дәвалау» программасы ярдәме белән республикада кимчелекле сабыйларны алдан ук ачыклап, аларга тиешле медицина ярдәме күрсәтеп була.

– Олылар арасында инвалидлык алучылар саны кимүгә бар. Республикада физик мөмкинлеге чикләнгән 269 меңнән артык кеше (сүз олылар турында бара. – **Ред.**) бар. Әлеге күрсәткечнең кимү сәбәбен илкүләм проектларның барлыкка килүе белән аңлатабыз. Вакытында диспансеризация үткәрелү, чирне вакытында күреп кисәтү инвалидлыктан коткара, – ди ул.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Министр әйтүенчә, сабыйлар арасында инвалидлык алу очраклары, киресенчә, арткан. 2017 елда аларның саны 14 мең булса, 2022 елда 17 меңгә җиткән.

Очрашуда инвалид бала тәрбияләгән өчен бирелә торган пособие күләменә дә тукталдылар. Әгәр бала I группа инвалид икән, аны тәрбияләүче әнигә 10 мең сум акча бирелә. Ә инде олы яшьтәге кешене тәрбияләүчеләргә 1200 сум акча түләнә. Янында караучы эшләсә, ул да түләнми башлый. Әлеге пособие күләмен бер күләмдә итәргә, әниләргә ярты көн яки онлайн эшләү мөмкинлеге бирергә кирәк, диделәр утырышта.

Эш дигәннән, республикада яшәүче инвалидларның 29 проценты хезмәткә яраклы яшьтә икән. Министр әйтүенчә, 31,6 мең физик мөмкинлеге чикләнгән кешенең эш урыны бар.

Очрашуда «Уңайлы мохит» программасы хакында да, балаларны укыту, аларның яллары, тернәкләндерү үзәкләрендә дәвалаулары, спорт белән шөгыльләнүләре, тукланулары, торак мәсьәләләре турында да сөйләштеләр. Фикерләр дә, тәкъдимнәр дә бар. Инвалидларга кагылышлы кайбер федераль законнарга үзгәрешләр дә кирәк. Татарстанның кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкиле Сәрия Сабурская барлык фикерләрне Дәүләт Думасы депутаты Татьяна Ларионовага тапшырачакларын әйтте.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Районнарда ни хәлләр?

Кукмара

Балыклы авылында башлангыч мәктәп бинасы төзелә. Бирелә сыйныф бүлмәләре, методик кабинет, ашханәдән тыш спорт залы да булачак. «Олыяз мәктәбенең филиалы булган әлеге белем йорты бик искергән, авария хәленә килгән һәм алга таба анда белем-тәрбия бирү эшчәнлеген алып бару мөмкин түгел иде. 2021 елның 22 октябрендә бирелә соңгы уку көне булды. Шуннан соң без, аерым сыйныф бүлмәләре билгеләп, укучыларны урта мәктәпкә күчердек», – ди Олыяз урта мәктәбе директоры Алмаз Гарипов. Мәктәп бинасының нигезе декабрьдә салынган. Белем йортының ачкычын 1 сентябрьдә тапшырырга ниятлиләр. («Хезмәт даны»)

Әгерҗе

Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулу уңаеннан, Әгерҗедә «Хәтер бакчасы» акциясе кысасында 1100 төп агач-куак утыртылды. «Олимп» спорт комплексы тирәсендәге скверга агач утыртуда район башлыгы Азат Вәлиев, имам-мөхтәсиб Габделкәрим хәзрәт Гыйззәтуллин, «Әгерҗе урманчылыгы» урманчы-җитәкчесе Владимир Ишморатов һәм башкалар катнашты. Уртак тырышлык белән нарат, юкә, миләш агач-куак үсентеләре утыртылды. («Әгерҗе хәбәрләре»)

Зәй

Быел Зәйдә «Безнең ишегалды» Президент программасы буенча 53 ишегалды төзекләндереләчәк. Шуның 8е авылларда һәм бистәләрдә урнашкан. Ишегалларда төзекләндерү эшләре башланды инде. Моның өчен районга 170 миллион сум акча бүлеп бирелде. («Зәй офыклары»)

Түбән Кама

Түбән Кама һәм Чаллы шәһәрләрен әйләнеп узу юлының икенче этабында сигез күпер һәм ике юлүткәргеч төзү планлаштырылган. Моннан тыш, бер транспорт чишелеше төзергә кирәк булачак. Ул Чаллы – Әлмәт юлы белән кисешкән урында булачак. Урап узу юлының озынлыгы 24 километр тәшкил итәчәк. Эшчеләр Келәтле елгасы аша күпер төзүгә керештеләр инде. Ә тагын җиде күпер Алан, Аулаш, Аштылга елгалары, шулай ук инешләр аша барлыкка киләчәк. Терәкләрне урнаштыруга әзерлек башланган. (e-nkama.ru)

Минзәлә

Быел Татарстан театрлар Сабан туе Минзәләдә үтәчәк. Аны 18 июньгә билгеләгәннәр. «Сабан туе программасына 13 уен кертелгән. Спорт ярышлары арасында соңгы елларда уздырылмаган волейбол ярышлары да бар. Әлеге турнир алдыннан Кама аръягы театрлары – Минзәлә, Чаллы, Түбән Кама һәм Әлмәт актерлары «Юбилейный» спорткомплексына зона ярышына җыелды. Нәтиҗәдә беренче урынны Чаллы командасы алды. Әлмәт – икенче, Минзәлә – өченче, Түбән Кама дүртенче булды. («Минзәлә»)

Әйтеп кенә бактым

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Читен хәл

Бер дус шалтырата: «Син – журналист, язучы да бугай әле. Озакламый шефның юбилее, тост әйтәсе була, матуррак сүзләр язып бир әле!» – ди.

– Синең шефыңны минем белгән дә юк, күргән дә юк, нәрсә языйм соң?

– Бер хайван инде ул, слушай. Но тост әйтмичә дә ярамый. Артык куштанланасы да килми, берәр нәрсә уйлап тап инде шунда.

– ...

– Да-а... синнән отказ булыр дип көтмәгән идем, – диде дә телефонын сүндерде бу.

Дөресен әйткәндә, миңа мондый гозер белән мөрәҗәгать иткәннәре юк иде. Дус та кызганыч, шефының бераз үзчирле, дуамал икәнен ишеткән бар иде. Үзен мактаганны бик яратуын да беләм.

Шөкер, үзем гомергә кемгәдер ярарга тырышмадым. Әтием дә шундый иде. Ә яратмаган кешесен читкә генә этеп куяр иде мәрхүм, әйтерсең лә «буяласы» килмәгән. Гомер буе күреп, сынап, күңелгә салып киләм: акыллы, тәрбияле, олпат кешеләр үзләрен мактаганны яратмыйлар. Киресенчә, уңайсызланалар, кызарып чыгалар. Чөнки алар үзләренең кем икәнен, нәрсәгә сәләтле (я сәләтсез) икәнен болай да белә. Андыйлар үзенә мәдхия җырлауга мохтаҗ түгел.

Тагын телефон шалтырады, теге дустым икән: «Башыңа берәр уй килмәдеме?» – ди. Ык-мык иткәләдем дә: «Бер фикер бар үзе», – дидем.

Дуска җан керде: «Язып җибәр, пажалысты!» – ди.

– Язмыйм, телдән генә әйтәм, үзең язып ал!

– Хәзер, кәгазь белән ручка гына алыйм. Тәк... Давай әйт!

– Хөрмәтле Фәлән Фәләнович, юбилеегыз белән! Әйдәгез шуның өчен...

– Дальше, – ди бу.

– Шуның белән шул, Сәләхиев Мәхмүт.

– Причем тут Мәхмүт?

– На всякий случай, – мәйтәм.

Шаяртуны әллә аңламады, әллә аңларга теләмәде бу. «Шуның белән шул, Сәләхиев Мәхмүт» дигән сүзләрне «Татарстан яшьләре»нең мәрхүм баш мөхәррире Исмәгыйль бик яратып әйтә иде. Берәр эшне матур гына башкарып чыксак, шул сүзләрне әйтеп көлешә идек. Гомумән, җитәкчеләрдән уңдым мин, әлеккеләреннән дә, бүгенгеләреннән дә. «Шеф»ка ошар микән дип эшләү уема да кереп карамады.

Хакимият кәнәфиләрендә утырганнарны гаепләргә җыенмыйм. Тик минем илдә түрәләр саны ишәю генә бераз уйландыра. Кайбер белгечләр әйтүенчә, хакимият вертикаленә омтылган саен, хөрмәтле җитәкчеләр саны арту табигый икән. Дәреслектә ни дәрәҗәдәдер, кайбер мәгълүматларга караганда, бүгенге Россиядә һәр 10 мең кешегә 102 түрә туры килә ди. СССР вакытында алар күпкә азрак булган.

Бүгенге җитәкчелек түрәләр санын киметергә омтыла үзе, тик нәтиҗә генә күренми. Ярый, юкка баш катырмыйк, үрчесеннәр, эшләсеннәр, алар да кеше бит. Тик минем җитәкчелектә «кәгазь боткасы» хакимлек итү генә күңелне сагайта.

Дәүләт хакимияте органнарында эшләүчеләр арасында танышларым шактый. Шуларның берсенә җитәкчесе бер эш йөкләгән. «Эш» дисәң, хәтере калыр, бер оешмага хат язарга кушкан булган. Ике атна узгач, әлеге танышымнан хат язмышы турында сораган, контрольгә ал, дигән.

Баксаң, әлеге хат бары тик дүртенче инстанциядә генә икән әле, тагын ике түрәнең укып чыгып имза куясы бар ди. «Бумажная волокита» дигән сүзләрне без балачактан ук ишетеп үстек, хәлләр бүген үзгәрмәде. Хакимият баскычларында утыручылар арасында үз эшен җиренә җиткереп башкаручылар булган кебек, эш күрсәткән булып кыланучылар да очраштыргалый. Миннән тост тексты язуны үтенгән дусның «шеф»ы да шундыйрак, күрәсең, аңа үзенең хуҗа икәнен төрле ысуллар, юллар белән һаман да раслап тору кирәк. Да-а... читен хәл инде бу.

Берничә көн узгач, шалтыраттым моңа. «Миңа үпкәләдең, ахрысы, хәбәрең юк. Юбилей ничек узды, шефың синең тосттан канәгать калдымы?» – дигән булдым. Әллә ни кәефе юк иде аның. «Кырын карап йөри башлады, малай. Эштән кумаса ярый инде», – диде. Читен хәл, әлбәттә.

АШНЫ ТАШ ИТЕП АТУ

24 февральдән соң безнең тормыш икегә бүленде: аңа кадәргегә һәм аннан соңгыга. Юк, мин бу юлы икътисади вазгыять турында язмыйм. Конфликт мәйданында барган фаҗигале хәлләр турында сөйләргә дә исәбем юк. Нәрсә булырга тиеш булса, шул булды: без 24 февраль таңында башка төрле чынбарлыкта уяндык. Кичә генә аны-моны уйламый яшәп яткан россиялеләрнең байтагы алдында дилемма куелды: тормышны ничек дәвам итәргә?

Россиядәге чит ил компанияләрендә хезмәт иткән яисә бизнесы башка илләр белән бәйле булган белгечләр зур кыенлыклар кичерә башлады. Санкцияләр нәтиҗәсендә зур-зур компанияләрнең ябылуы, чикнең теге ягы белән акча алмашу кыенлыклары мөһаҗирлек мәсьәләсен көн тәртибенә бастырды. Күп кенә технологик компанияләр Россия базарын ташлап китү генә түгел, интеллектуаль хезмәт осталары булган белгечләрне дә үзләре белән алып китүне максат итте. Алар гына түгел, Россиянең үз компанияләре дә офисларын бүтән мәйданнарда ачуны кулай күрә башлады. Шундый көннәр булды: кайсы илгә күчү мәсьәләсе хезмәткәрләр арасында тавышка куелды. Мин үзем, мәсәлән, «Сербиягә күчәргәме, Төркиягәме?» дигән сорауны тавышка куйган Казандагы компанияне беләм.

Аңлашыла инде: «дус ил»ләрнең кайсында булса да якорь салу максат итеп куелды. Безгә санкцияләр керткән Көнбатыш илләренә күчү турында сүз дә куертып тормадылар, чөнки визалар бирелми, чикләр бикләнгән. Дөрес, хәзер Вашингтонда да, кыйммәтле белгечләргә виза биреп, Россияне технологик яктан коргаксыту сәясәте үткәрергә җыеналар. Тагын шунысы бар: ноу-хау өлкәсендә көч түгүчеләр гадәттә космополит булалар, Ватанга берегеп яшәү – алар өлеше түгел. Моңа гаҗәпләнергә кирәкми, чөнки профессияләре шуны таләп итә. Бикләнеп яшәп, яңа югарылыкка ирешә алмыйсың. Менә «Яндекс» дип аталган Россиянеке булып саналган компания бар бит әле. Теркәлүен ул чит илдә теркәлгән. Хәзер төп офисын ачу өчен яңа мәйдан эзли, гыйбриләр арасына барып, Израильгә кысылмакчы. Хәзерге шартларда Мәскәүдә эш алып бару, күрәсең, мөмкин түгелдер. Бу мәсьәләнең уңай һәм тискәре якларын да санарга җыенмыйм әле мин. Башка мәйданга барып төштеңме, иң беренче милләтләр арасында мөнәсәбәт баш калкытмый калмаячак. Сиңа караш нинди булачак? Дилемманың менә шундый ягы да бар бит әле. Әйтик, Грузиягә барып төшкән россияле белгечләр банк хисабы ачу өчен үз өсләренә байтак кына йөкләмәләр алырга, тиешле кәгазьгә имзаларын салырга тиеш, диләр. Грузиннарның да аңларга була: «русский мир»ның үзләрендә баш калкытуын теләмиләр.

Югарыда искә алынган Казан компаниясендә төпләнү мәйданын сайлауда тавышлар икегә бүленде, диләр. Мөселманнар Төркияне сайлау ягын куәтләсә, тамырларында славян каны агучылар Сербия ягын каерганнар. Сайлау өчен мәйдан бик тар булганга, ялгыз күчүчеләр Урта Азиянең элекке совет республикаларына күчәргә мәҗбүр булганнар. Проблеманың матди ягы да бар бит әле: валюта курслары, банк хисабы ачу, «Мир» картасыннан файдалана алу мөмкинлеге – яшәү өчен котылгысыз кирәк булган нәрсәләрнең барысын да исәпкә алмый булмый. Фатир арендалау хакына кадәр мөһим. Әле Россиядән килгәннәргә арендага торак бирәләрме-юкмы, хәлнең шундый ягы да бар.

Хәзер инде әйдә төп мәсьәләгә күчик. Бездәге Урта Азиядән килгән мөһаҗирләргә мөнәсәбәт ничегрәк булуын беләбез бит инде. Йомшак кына итеп әйткәндә, бик үк яратып бетермиләр. «Чурка» дигән сүзне беләсездер. Россиялеләрнең ул сүзне кайсы милләтләргә карата кулланылуы да мәгълүм. Рус теленнән башка берни дә белмәгән егетләрдән сораганым бар ул сүзнең мәгънәсен. Ни аңлатуын белмиләр. «Чурка» – агач кисәге ул, безнеңчә әйтсәк, утын түмәре. Күчерелмә мәгънәдә томана, берни дә аңламый торган кешегә карата кулланыла. Безнең айти егетләрнең байтагы яшәү мәйданы эзләп менә шул «чурка»лар ватанына барып төште.

Мәгълүмдер ки, Урта Азия – элекке мөселманнар мәйданы. Ислам совет чорында ул төбәкләрдә шулай ук югалып бетә язган булса да, аның канга сеңгән әхлакый кыйммәтләре барыбер сакланган. Аннан соң хәзер дин яңарыш чоры кичерә бит. СССР таркалган елларда булды инде аларда да хәлләр. Идеаллаштырырга ярамый бер нәрсәне дә. Әмма ярсу өянәге үткәч, барысы да үз урынына утыра. Халыкларының төп милли сыйфаты үз сүзен әйтми калмый. Ислам доктринасында исә өч әхлакый сыйфат калку булып күзгә ташлана: бер халык икенчесеннән өстен түгел, расалар да шулай ук: ак тәнле кара тәнледән югарырак булып саналмый; өлкән кеше хөрмәткә ия; кунакның статусы шулай ук югары. Хәзерге секуляр, ягъни диннән аерылган дәүләтләрдә бу кагыйдәләр сакланмый, билгеле, әмма халык дипломатиясендә онытылмаган әле алар. Бу юллар авторының гарәп дөньясында ак сакалы сәбәпле киң хөрмәттән файдаланганы бар: җәяү йөртмәскә тырышалар, кибетләрдә чиратсыз үткәрәләр, кафедра сыйлап чыгарырга чакырулары да мөмкин. Синең тел белмәвең, кайсы халыктан булуың кызыксындырмый берәүне дә. Аңгыраеп торуың өчен утын түмәре дип атамыйлар. Чит мәйданда, тел аңламаганда, томана булып күренү бер дә кыен түгел.

vk.com

Безнең рус телле егетләр көтмәгәндә менә шундый традицияләрнең югалтып бетермәгән халыклар арасына барып төште. Беренче реакция – гаҗәпләнү. Менә «Фейсбук»та шул егетләрнең берсе ниләр яза. Кыска гына өзеген оригиналь телдә бирик әле: «Сейчас мы заново открыли для себя Узбекистан. Массово оказавшись там по той же самой причине, по которой советские люди очутились в Ташкенте в 1941 году… Жители России начинают открывать для себя узбеков. Они совсем другие. Неподдельно добрые, уважительные, искренние. Первое время срабатывает режим подозрительного – в чем подвох? Когда становится понятно, что его нет, и узбеки такие на самом деле, приходит неизбежное сравнение с оставленной Родиной. Почему мы жестокие, озлобленные, угрюмые, с подлой готовностью написать донос, потребовать казни, обрадоваться чужому горю?..»

1941 елдан алда 21 елгы ачлык бар әле. «Ташкент – город хлебный» кинофильмын хәтерлисездер. Ач үлемнән кайнар туфраклы якларга барып, күпме рус кешесе исән калды икән ул елларда? Ул саннарны статистика исәпкә алмый.

Кешелеклелек хисе табигый рәвештә бар халыкларда да саклана ул. Явыз идеологияләр кеше табигатен үзгәртергә, аны ерткычка әйләндерергә күпме генә тырышмасын, гади халык катлауларында ярдәмчеллек, нечкә күңеллелек, шәфкатьлелек хисләре яши, тормышның катлаулы мизгелләрендә үз сүзләрен әйтә. Шулай да төрки мөселман халыкларда ул сыйфатлар күбрәк өстенлек алган кебек тоела. Татарның «Таш белән атканга аш белән ат» дигән яшәү кагыйдәсе тиктомалдан гына барлыкка килмәгән.

Сталин терроры хакимлек иткән елларда, кешеләрне гаиләсендә «халык дошманы» булган өчен генә дә этаплар белән озаткан чакларда, милләте буенча немец булган Гертруда Платайс истәлекләре дә югарыда язылганнарны дәлилли кебек. Аның гаепләнү маддәсе да ЧСИР, ягъни «член семьи изменника родины» дип атала. Менә шундый маддә белән хөкем ителгән Гертруда Платайс тоткын буларак Казахстан даласына китерелә. Көчле салкыннарда тоткыннардан барак төзү өчен кул буенда камыш җыйдыралар, тәүлеккә 20 сәгатькә кадәр эшләргә туры килә. Камышлар арасыннан картлар һәм балалар сикереп чыгуын һәм үзләренә таш ата башлауларын искә ала ул. Берничә көн әхлакый яктан шул рәвешле тапталган һәм изелгәннән соң, хәлдән тайган немец хатыны йөзе белән шул ташларның берсенә егыла. Борынына эремчек исе килеп бәрелә. Эремчекне киптереп корт ясыйлар бит әле бездә дә. Казах картлары конвоирларның уяулыгын балалардан ашны таш итеп аттырып алдаган икән. Үзләре дә ачлы-туклы яшәгән казахларның бу эчкерсез ярдәмен Гертруда Платайс беркайчан да онытмый, соңыннан хисләрен «Курт – драгоценный камень» дигән шигырь юлларына сала. «Я прошла все круги ада, Потеряла веру и друзей, Но одно я знаю, Что только так и надо воспитывать детей», – дигән юллар бар ул шигырьдә. Барлык балалар да шундый тәрбия аша үтсә, без бүген дөньяда бара торган бик күп вәхшилекләрнең шаһитлары булмас идек.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

ӘХЛАКЛЫ КАЛӘМ

Журналистлар урамында – бәйрәм. Каләм әһелләрен Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин котлады. Тантанада «Татмедиа» агентлыгы җитәкчесе Айдар Сәлимгәрәев һәм Журналистлар берлеге рәисе, «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе генераль директоры Илшат Әминов та катнашты.

Бәйрәм очрашуы Матбугат йортының яңартылган бинасында узды. «Биредә үзенчәлекле мохит хөкем сөрә. Бу – 30 нчы елларда төзелгән уникаль архитектура һәйкәле. Бина республиканың матбугат һәм китап басу тарихы белән тыгыз бәйләнгән», – диде Фәрит Мөхәммәтшин.


tatarstan.ru

Дәүләт Советы Рәисе әйтүенчә, цифрлаштыру киң җәелүгә карамастан, басма матбугат чаралары да хакимият белән җәмгыять арасында мөһим аралашу чарасы булып калуын дәвам итә. Бүген республикада 725 массакүләм мәгълүмат чарасы теркәлгән. Шуларның 390ы – басма матбугат чаралары. Татар телендә 113 газета, 43 журнал нәшер ителә. Илдә тиражлар кимегәндә, Татарстан – матбугатка язылучылар буенча алдынгылар арасында. Сүз уңаеннан, быел республика районнарында 15 почта бүлекчәсен яңартырга җыеналар.

Заманча мәгълүмат чыганакларына килгәндә, халыкның интернет-ресурсларга һәм социаль хезмәтләргә ышанычы 10 ел эчендә дүрт тапкыр арткан. 2021 елда бу күрсәткеч 20 процентка җиткән. «Цифрлаштыру елында да санлы трансформацияне үстерү буенча бурычлар зур», – диде Дәүләт Советы Рәисе.

Эшебез шундый булгач, Фәрит Мөхәммәтшин дөньядагы хәлләрне дә урап уза алмады. Аның фикеренчә, вакыйгаларны анализлап, рейтинг артыннан кумыйча, аларны дөрес итеп яктырту кирәк. «Үзебезнең традицияләргә һәм рухи кыйммәтләргә тугрылык, бер команда булып нәтиҗәле эшли белү безгә теләсә нинди кыенлыкларны җиңеп чыгарга ярдәм итәчәк. Бу мәгълүмати көрәштә сез – безнең төп таянычыбыз», – диде парламент җитәкчесе.

Бу үзгәрешләр журналистикага ничек йогынты ясый? «Татарстан» дәүләт телевидение һәм радиотапшырулар компаниясе директоры Фирдүс Гыймалтдинов әйтүенчә, бәлки, журналистиканың бердән-бер стиле, халыкка җиткерү чаралары үзгәрәдер. Ләкин аның нигезендә халыкка хезмәт итү һәм гуманлылык ята.

– Безне журналистика факультетында әхлаклы булырга өйрәттеләр. Журналистның төп бурычын халык мәнфәгатьләрен яклап, хезмәт итү дип саныйм. Әлбәттә, бүгенге чара – остазларыбызны искә төшерү, исәннәре белән очраша торган көн. Матбугат көне минем өчен шул яктан кадерле. Сәгать укларын чагыштыру чарасы, – диде Фирдүс Гыймалтдинов.

«Матбугат.ру» порталы җитәкчесе Данил Сафәров фикеренчә, журналистиканың формалары үзгәрә башлады. «Кайда журналистика, кайда социаль челтәрләр, кайда мессенджерлардан килгән хәбәрләр... Барысы да үзгәреш кичерә. Бәлкем, без әле үзгәреш башында гынадыр. Кая барып чыгасын дөнья күрсәтер», – ди ул.

Сәрия МИФТАХОВА

УКЫГАН БЕЛМИ, САНАГАН БЕЛӘ

Бүген журналистиканы интернеттан аерып карау мөмкин түгел диярлек. Безгә хәзер тиз кирәк, игътибарны да җәлеп итсен – заманы шундый чөнки. Ә интернет басмаларның бу таләпләрне үтәрлек барлык мөмкинлекләре бар.

Проблемалары да юк түгел, билгеле. Матбугат көне алдыннан Журналистлар берлегендә татар телендәге интернет журналистикасы турында фикер алыштылар.

Очрашуның тагын бер сәбәбе – быел татар интернет журналистикасы тарихын беренчеләрдән булып яза башлаган «Интертат» электрон басмасы 20 еллык юбилеен каршылый. Шул уңайдан Журналистлар берлегендәге Татарстан журналистикасы тарихы музеенда «Интертат»ка кагылышлы документлар, тарихи фотосурәтләр тәкъдим ителгән стенд ачылды.

«Татмедиа» республика агентлыгы җитәкчесе Айдар Сәлимгәрәев, татар интернет чараларын укучылар елдан-ел артып бара, дип искәртте.

– Яшәешнең төрле өлкәләрендә татар мохитен саклау әле дә җитди мәсьәлә булып кала бирә. Шунысы сөендерә: татар телле сайтлар, социаль челтәрләрне караучылар елдан-ел арта. Социаль челтәрләрдә татар сайтларының 1,7 млн язылучысы исәпләнә. Бу җәһәттән системалы рәвештә һәм бик нәтиҗәле эшли торган басмаларыбызга рәхмәт, – диде ул.

Журналистлар берлеге рәисе Илшат Әминов, кимчелекле якларыбыз, эшлисе эшләребез күп, диде. «Иң күзгә ташланганы – кадрлар мәсьәләсе. Бүген һәркем үзенә кадр әзерли башлады. Безгә берләшергә кирәк. Яшь журналистларга ихтыяҗ елдан-ел артачак кына», – диде ул.

«Интертат» электрон басмасы һәм «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгының татар редакциясе баш мөхәррире Рәмис Латыйпов, бүген татар телендәге интернет журналистикасын бер миллионнан артык кеше укый, диде. Аның фикеренчә, журналистиканың абруен күтәрергә телибез икән, берничә мәсьәләгә игътибар итү зарур:

– Безгә «тренд»ларны вакытында «эләктереп алып», вакытында тормышка ашырырга кирәк. Эш урыннары, хезмәт хакы турында да уйлау комачауламас. Аннан соң, бәлки, безгә читкә йөз тотар вакыттыр? Чит илләргә, төбәкләргә барып, тәҗрибә алмашу журналистларга киңрәк фикерләргә ярдәм итәр иде.

Рәмис Латыйпов татар матбугат чараларының яңалык порталларына чыга алмавын да искәртте. Аның бу фикерен газетабызның баш мөхәррире Гөлнара Сабирова дәвам итте:

– Без рус сайтлары файдалана алган мөмкинлекләрдән файдалана алмыйбыз. Мәсәлән, шул ук «Яндекс.Новости» рубрикасында махсус татарча сәхифә булса, бу татар матбугат чараларына үсәргә мөмкинлек бирер иде. Бу проблемага, һичшиксез, игътибар итәргә кирәк дип уйлыйм.

Ул шулай ук «ВТ» мисалында интернеттагы эшчәнлекнең басма матбугат чарасына йогынтысы, интернетның кайбер кимчелекләре турында сөйләде.

– Гомумән, интернетта эшләү турында сөйләгәндә,ниндидер махсус кагыйдәләрне әйтү урынсыздыр. Һәр матбугат чарасының үз аудиториясе бар, димәк, шаблоннар белән эшләү мөмкин түгел. Ләкин үзебезнең мисалда шуны әйтә алам: интернет газетаның функциясен, тарату каналын, аудиториясен киңәйтергә, ә журналистларга яңача эшләргә, күнекмәләрен арттырырга этәргеч ясады. Бүген «Ватаным Татарстан» газетасы сайтын тәүлегенә 8,5–9 мең кеше укый. Татар сайтлары арасында без – икенче-өченче урында. Тик цифрлашу тизрәк барган саен, аның аркасында пәйда булган проблемалар да арта. Сер түгел, сан артыннан куу сыйфатның кимүенә китерә. Инде хәзер сыйфатка игътибар итәргә вакыт җиткәндер, – диде ул.

Интернетта эшләүнең сер йомагы сүтелә торды. «Шәһри Казан» газетасы баш мөхәррире Радик Сабиров фикеренчә, бүген журналистларга «хулиганлык»тан курыкмаска кирәк. «Без бик тыйнак инде. Әйтик, безнең «итәк асты» темасына язылган бер материалны сүкмәгән кеше калмады. Ләкин шул ук вакытта шушы ук язманы, егылып китеп, 50 мең кеше укыды», – диде ул.

Рәмис Латыйпов атаган санны кабат искә төшерик әле. Шушы бер миллионлык аудиториянең 430 меңе – интернеттагы татар текстларын «төбенә төшеп», аңлап укучылар һәм аларга карата үз фикерен белдерә алган кешеләр. «Татмедиа» акционерлык җәмгыятенең социаль медиалар буенча директоры Алсу Исмәгыйлева шулай дип белдерде. «Түгәрәк өстәл»дә катнашучылар арасында бу мәсьәлә аеруча бәхәс уятты. Татарларның гомуми саны белән чагыштырганда, бу санны аз, дип әйтүчеләр дә, булганына шөкер итүчеләр дә табылды. «Мондый мәгълүматка ия булу өчен безнең техник мөмкинлекләр бармыни?» – диючеләр дә булды.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Автор фотосы

ТАТАРСТАН МАТБУГАТЫ – ЭНЦИКЛОПЕДИЯДӘ

Журналистлар берлегендә Татарстан журналистикасының ачык онлайн энциклопедиясен тәкъдим иттеләр.

Аны әзерләү эше инде күптән башланган. Башлап йөрүче кеше – берлекнең элеккеге рәисе, Дәүләт Советы депутаты Римма Ратникова әйтүенчә, бу хакта ун еллап фикерләшкәннәр. Ә берничә ел элек Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институтына мөрәҗәгать иткәннәр.

– Без аны башта китап булыр дип күзаллаган идек. Тик тормышта барысы да бик тиз үзгәрү сәбәпле, электрон энциклопедиягә тукталырга булдык. Бу – безнең зур уртак хезмәтебез. Энциклопедияне булдыруда катнашучы, әлеге идеяне хуплаучы барлык кешеләргә зур рәхмәтемне белдерәм, – диде Римма Ратникова.

tatjur.ru адресы буенча урнашкан энциклопедиядә бүген 386 мәкалә, 355 шәхес турында мәгълүмат бар. Ул «Википедия» форматында эшләнгән, үз эченә XIX гасыр һәм XX гасырның беренче яртысын алган. Аны техник яктан «Сәләт» яшьләр оешмасы эшләгән. Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты директоры Искәндәр Гыйләҗев фикеренчә, электрон энциклопедиянең үз өстенлекләре бар. «Татарстан журналистикасының үз энциклопедиясе булу – бик мөһим вакыйга. Журналистлар берлеге белән әлеге иҗади хезмәттәшлегебезнең алга таба да яхшы дәвамы булыр дип ышанам», – диде ул.

Энциклопедия ачык һәм ул даими тулыландырылып торачак. Татарстан Журналистлар берлеге рәисе Илшат Әминов әйтүенчә, фикер-тәкъдимнәрне Президиум әгъзалары караячак, шуннан соң мәкаләләр урнаштырылачак. «Әлегә эшне башладык кына. Татарстан журналистикасы энциклопедиясе яшь буынга бай мирасыбызны тапшырырга тиеш», – диде ул.

Ләйсән САФИНА

АВЫЛ КҮРКЕ

Автор фотосы

Кайчандыр үткәннәрнең истәлеге, киләчәкнең зәңгәр хыялы булган тарихи ядкарь ул. Хәзер исә – авылның гына түгел, Татарстанның горурлыгы да. Сүзебез – Әтнә районындагы Түбән Бәрәскә авылындагы мәчет хакында. Казан ханлыгы яулап алынганнан соң татар җирендә таштан төзелгән иң беренче гыйбадәтханә ул. Гасырлар шавын саклаган мәчетне без дә күреп кайттык.

…Мәчетне күрми калу мөмкин түгел. Күз төшүгә: «Урынын да сайлый белеп сайлаган бит элеккеләр!» – дип куясың. Һичшиксез, мәһабәт бина булып торсын, бар дөнья күрсен, авылга мәчет манарасы аша нур иңсен дигән максаттан салганнардыр аны. Бу авылда диннең ни дәрәҗәдә көчле булуын тарих үзе үк раслый. Мәчетнең данын исә һәркем белә. Тарих йомгагын сүтүдә безгә юлдашыбыз Сәрия Хәйруллина булышты.

Әби патша рөхсәте белән

Мәгълүм булганча, Әтнәдән тыш, Татарстанда таш мәчетләр Казанда, Арчаның Кышкарында һәм Кукмараның Мәчкәрәсендә салына. Түбән Бәрәскәдәгесе – иң беренчесе. Ул Казанның данлыклы «Мәрҗани» мәчетеннән бер елга алданрак – 1769 елда төзелә.

Тарихи чыганакларда язылганча, 1742–1744 еллар аралыгында Татарстан территориясендә 400дән артык мәчет яндырылып, юкка чыгарыла. Көчләп чукындыру сәясәте башлана. Денсезлек артып, миллилек, иман нуры сүрелә барган дәвер…

Россия белән Екатерина II идарә иткән чорда мөселманнарга карата хәерхаһлы мөнәсәбәт шәйләнә башлый. 1766 елда Әби патша Казанга килә һәм халык белән очраша, татарларның зарүтенечләрен тыңлый. Соңрак Екатерина II ике мәчет салырга рөхсәт бирә. Аңлашылганча, шуның берсенә нигез Түбән Бәрәскә авылында салына. Иман йортын шушы авыл сәүдәгәре Ибраһим Борнаев төзетә. Салада мәчет төзелү турында күренекле мәгърифәтче Шиһабетдин Мәрҗанинең «Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр» исемле танылган тарихи хезмәтендә: «Авыл уртасындагы таш мәчетне шул авыл кешесе Ибраһим бине Йосыф бине Әснай бине Исәнкол бине Борнагыл 1183 (1769) ел азагында бик нык итеп, баскычларын чуеннан ясатып салдырган», – дип язып калдыруы да билгеле.

Иске тормышны җимергәндә…

…мәчет ташы кирәк була! Тарихның шундыйрак күңелсез битләре дә бар шул.

Совет чорында гыйбадәт урыннарын дәүләт ихтыяҗлары өчен файдаланулар мәгълүм. 1930 елда Олы Әтнә авылы район үзәгенә әверелә. ВКП(б)ның Әтнә райкомына бина кору өчен кирпеч юнәтергә кирәк була. Түбән Бәрәскә мәчетен җимереп, кирпечләреннән файдаланырга уйлыйлар. Иман йортының гөмбәзен, икенче катның бер өлешен җимереп, кирпечләрен Әтнәгә ташый башлыйлар. Әмма диварга тешләре үтми. Сөйләүләренә караганда, аны төзегән вакытта измәсенә йомырка сарысы кушкан булганнар.

> Диндарлар мондый кыргыйлыкка ничек түзсен ди инде?! Авылдан берәве (изге күңелле кешенең исемен генә хәтерләмиләр) үз акчасына Казаннан кирпеч ташытырга тотына һәм шул рәвешле мәчетне тулысынча җимерелүдән саклап кала.

Әлбәттә, мәчетнең элеккеге матурлыгын кайтарып булмый: катлаулы геометрик фигуралы тәрәзәләрне туры почмаклылары, гадирәкләре алмаштыра, ишелгән гөмбәзне дә үз хәленә кайтарырлык осталар табылмый, гади түшәм генә җәелә, дивар төзекләндерелә. Ә бит боларның барысына да үз вакытында тиңнәр булмый…

Зәңгәр хыял

Мәчет ишеге 150 ел буе ачык була. Әйткәнебезчә, үткән гасырның 30 нчы елларында ябылып, аны клуб итеп үзгәртәләр. 2010 елга кадәр шул вазыйфаны башкара әле ул. Тик гыйбадәт урынын кайчан да булса үз халәтенә кайтарырга кирәк бит инде. Ядкарь, кадерле, бәһасез истәлек буларак та, иман йорты буларак та әһәмиятле.

Түбән Бәрәскәнең бу җәһәттән бәхете бар. Төзекләндерергә кирәк дип, бу эш белән чын мәгънәсендә янып йөрүчеләр була. Җитәкчелеккә дә чыгалар, тарихи әһәмиятен дә аңлаталар, чарасын да күрәләр. Искене төзәтү яңаны сафка бастырудан күпкә авыррак та бит әле ул. Әмма күз курка, кул тәвәккәлли, диләрме? 2020 елның 11 декабрендә бу авылны яңгыратып, борынгы яңа мәчеттән азан тавышы яңгырый.

Татарстанның иң борынгы мәчетенең хәзерге күркәм торышына авылдагылар да күп көч куйган, билгеле. Төзекләндерү эшләренә киткән акчаны да санамыйлар, иң мөһиме – күңелдәгесе, ният.

Илгиз Хәйруллин – изге эшне башлап йөрүчеләрнең берсе. Мәһабәт иман йортының яңадан сафка басуына сөенеп туя алмый ул хәзер. Ничә ел күңелендә йөрткән хыялы бит ул аның. 30 елдан артык Ленин исемендәге күмәк хуҗалыкны җитәкләгән кешенең, бәлки, авылда башкарган эшләренең иң зурысы да, гомер иткәндә кичергән вакыйгаларның иң сөенечлесе дә мәчетне торгызу булгандыр.

– Шушы мәчетне төзекләндерү безнең өстә торган зур бурыч иде. Шөкер, мондый көнгә дә ирештек, – ди ул шатланып. – Үз гомеремдә башкарган эшләрнең иң зуры, иң мәгънәлесе шушы мәчет ачылышы булгандыр, дим. Яшибез-яшибез дә, бу дөнья белән генә чикләнми бит әле ул тормыш. Вакытында намазын укып, мәчеткә йөргән кеше – бәхетле кеше. Без исә – гомер арбасында чабучылар. Адәм баласының зур кимчелеге инде бу.

…Әйе, мәчетләрне бизәп, чуарлап ясарга да мөмкин. Бәрәскәдәгесе андый түгел. Артык берни юк анда. Әмма хикмәт бит анда түгел. Бу дөньядан киткәнче, таш мәчеттән азан тавышын ишетеп калырга хыяллanучылар бер-ике генә булмый салада. Инде хыяллары чынга ашты. Мәчеткә илткән юлны гына суытмассыннар да тарихи ядкарьнең кадере генә бетмәсен. Бу ярамый да! Мәчет бит ул тарихи корылма гына түгел, ул – иң элек дин тотучыларның җыелу урыны. Аңа йозак эленеп торырга тиеш түгел. Сүз уңаеннан, Бәрәскә мәчетенә җомга намазына 35–40 кеше йөри. Өлкәннәрдән күреп, яшьләр дә иярмәсме дигән өмет-хыялы яши бирәдәгеләрнең. Хак юл, иртәмесоңмы, үзенә дәшәчәк ул. Мәчеттә музей да бар. Авыл халкының үз көче белән җыелган тарихи ядкарьләр урын алган анда. Димәк, гыйбадәт урынының туристларны җәлеп итәр мөмкинлеге дә бар дигән сүз. Иң мөһиме рухын саклый алганнар. Ясалма, декорацияләргә бай чорда әнә шунысы да әһәмиятле бит әле.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Минем өчен ислам…

Камил ИСХАКОВ, Болгар ислам академиясен гамәлгә куючылар советы рәисе:

– Без атеизм чорында үстек. Әмма шуңа да карамастан, безнең өйдә дин һәрчак булды. Шуңа күрә Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителүгә 1100 ел тулу – безнең өчен, бөтен ил өчен бик зур вакыйга. Россия Президенты Владимир Путинга рәхмәт. Аның указы нигезендә әлеге вакыйга дәүләт бәйрәме дәрәҗәсендә уздырыла. Ислам динен кергән вакытта Болгар дәүләтендә төрле диннәр булган. Безнең ул чордагы җитәкчеләр алга карап эш иткән. Ислам дине боерык, күрсәтмә белән кермәгән. Безнең бабайлар аны үз теләге белән, ихтыяри рәвештә кабул иткән. Ул вакытта тамчы-тамчы гына булып кертелгән ислам дине бүген инде бөтен Җир шарын колачлый. Мин Ислам Конференциясе Оешмасы каршында Россиянең даими вәкиле булып торганда дөньяда 1 миллиард 300 миллион мөселман исәпләнә иде. Ун ел эчендә ул 2 миллиардка җитте. Динебез әнә шундый зур тизлек белән тарала, бөтен дөньяны колачлый. Киләчәктә ислам дөнья күләмендә тагын да үсәр дип уйлыйм. Менә шушы мирасыбызны кадерләп саклап, аны киләчәк буыннарга да җиткерәсе иде. Балаларыбызны тәрбияләгәндә, тормыш-яшәешебездә аңа таяну юнәлешендә безгә бик зур эшләр башкарырга кирәк. Ислам дине без – мөселманнарны гына түгел, башка диннәрне дә берләштерә.

Марат ӘМИРХАНОВ, язучы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре:

– Ислам дине кабул ителүнең әһәмияте бик зур. Ник дигәндә, ислам дине башланган чорда ук тәрәккыят нигезендә калкып чыккан. Ислам динен тоткан барлык халыклар мәдәният ягыннан да, икътисад, үз-үзләрен тотышы, рухи-этик яктан да башкалардан аерылып торган. Шуңа күрә дөньяда ислам динен тоткан халыклар, милләтләр, безнең җәмгыятьне алып баручы төп көч булган. Ул әле дә шул позициясен саклый. Ислам диненең иң мөһим тагын бер әһәмияте бар. Ул халыкларны бер учка җыеп тота, аларның бердәмлеген саклый. Шуңа күрә бу көн – безнең өчен дә, башка халыклар өчен дә әһәмиятле вакыйга. Ата-бабаларыбыз аны кабул итеп бик дөрес эшләгән. Пакьлек, чисталык ягыннан да ислам дине, һичшиксез, башка диннәрдән аерылып тора. Шул ук исерткеч эчемлекләр эчү мәсьәләсендә бик катгый тора ул. Шәхсән үзем дә аның бу ягын хуплыйм.

Рөстәм хәзрәт ХӘЙРУЛЛИН, «Гаилә» мәчете имам-хатыйбы:

– Халкыбызны берләштерә торган вакыйга, бәйрәм бу. Ислам ул – безнең тормыш, яшәү рәвеше. Дин ул – мәчеттә генә түгел, ул урамда да, кибеттә дә, базарда да. Бөтен җирдә мөселман. Шул рәвешле Аллаһы Тәгалә безне бөтен җирдә күрә. Без иң беренче чиратта әнә шуны сизеп яшәргә тиеш. Шөкер, без – тирән тарихлы халык. Киләчәктә дә үз тарихыбызны, үз буыннарыбызны онытмыйча, аларны өйрәнергә кирәк. Шуңа өстәп әле без – мөселманнар – бердәм халык. Аллаһы Тәгалә алдагы көннәрдә дә шушы сыйфатыбызны саклап, үзебезнең тамырларны онытмыйча, догалы булырга насыйп итсен. Киләчәк турында уйлап, 100, 1000 елдан соң оныкларыбыз безгә дога кылырмы, дигән фикер белән балаларыбызны безгә догачы булырлык итеп тәрбияләргә, яшәргә насыйп булсын.

Гөлназ ГӘРӘЕВА, укытучы (Мамадыш районы Көек-Ерыкса авылы):

– Безнең авылда дин мәсьәләсе бик югары куелган. Гыйлемле имамыбыз да бар, өлкәннәребез, яшьләр, балалар да күп. Мин үземне татар дип кенә түгел, мөселман дип исәплим. Җаным-тәнем белән Аллаһы Тәгаләнең бар һәм бер икәненә ышанам. Әмма үземне ислам диненең барлык кануннарын үтәп яшим дип әйтә алмыйм. Намазда түгелмен, тик һәр эшемне «бисмилла» белән башларга тырышам. Тормышымда бар булганы өчен Аллаһка шөкер итеп, рәхмәтемне җиткерәм. Кешедә яхшылыкка ышану яшәргә тиеш дип уйлыйм. Ислам дине минем өчен зур әһәмияткә ия. Аның бар кануннарын үтәп, тик күңелдән дин тотучыларны хөрмәт итәм, аларның ихтыяр көче алдында баш иям, үзем дә шул халәткә җитә алырмын дип ышанам. Һәр гамәлемне, сүземне Аллаһ ризалыгы өчен дип эшлим. Тик һәр ышануның чиге булырга тиеш, ул сектант дәрәҗәсенә җитеп, дәүләттән аерылу, кешеләргә начарлык эшләүгә барып җитәргә тиеш түгел.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ТЫНЫЧЛЫК ИҢДЕРҮЧЕ ДИН

Идел Болгарстанында ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгы – халкыбыз өчен зур вакыйга. Ниһаять, дулкынланып көткән бәйрәм көне килеп җитте. Күптән түгел генә Татарстан мөфтие урынбасары Илфар ХӘСӘНОВ ярдәме белән без укучыларыбызны әзерлек эшләре белән таныштырган идек. Бүген исә әби-бабаларыбыз мең ел элек кабул итеп тә, үз көчен югалтмаган ислам диненең бүгенге тормышыбызга йогынтысы турында сөйләшергә булдык.

tatarstan.ru

:: Илфар хәзрәт, кешелек өчен 1100 ел – бик зур сан инде ул. Тарих төпкеленә күбрәк төшкән саен, гаҗәпләнү арта гына бара. Чор белән чор алышынган. Кайбер дәүләтләр җимерелгән, халыклар бөтенләй юкка чыккан. Әмма нинди генә авыр шартлар булмасын, әби-бабаларыбыз буыннан-буынга рухи байлыгын саклап кала алган. Мондый озын юл үткән ислам диненең инандыру көче нидә?

– Ислам дине – хак дин, ул хаклыкны эзли, дәлилли, ягъни мәсәләне, сукыр инануга корылмаган. Аның бөтен көче дә шунда. Кешелек үзе дә Аллаһ тарафыннан фикер йөртүгә сәләтле булып яратылган бит. Чыннан да, адәм баласы кылган гамәлләрен дәлилли алмаса, инануы да бик көчсез булыр яки бөтенләй юкка чыгар иде. Иманның көчле булуы әнә шуннан килә. Һәр мөселман Аллаһы Тәгаләнең барлыгына, берлегенә ышанырга тиеш. Бу – беренчедән. Икенчедән, Аллаһ, Изге Коръән китабын саклап калырмын, дигән. Исламның күп гасырлык тарихы үзе үк моны раслый. Бүген ул Россия Федерациясендә төп диннәрнең берсе булып санала.

:: Бик еракка китмичә, хәтта йөз ел элек булган хәлләргә күз салсак та, Татарстан, Идел буенда урнашкан территорияләрдә ислам дине төрле шартларда яшәргә мәҗбүр булды. Аны юкка чыгарырга да тырыштылар, көндәшлеккә дә дучар иттеләр. Көчләп чукындыру чорлары булды. Атеизм белән мавыгып алдык. Мондый шартларда ислам диненең сафлыгын ничек саклап калырга мөмкин булды икән?

– Совет елларында безнең муллалар, ишаннар, имамнар сөргеннәргә куылды, үлемгә хөкем ителделәр. Әмма түздеrange, Аллаһы Тәгаләгә хыянәт итмәделәр. Бөек көчне бар дип белүчеләрнең иманы нык иде. Сез үзегез дә минем белән килешәсездер дип уйлыйм.

> Нинди генә шартларда да дин юлыннан тайпылмаган кешеләр һәр авылда бар иде. Мәчетләрнең манарасын кисеп, тартып алынганнан соң да, авыл картлары җомга намазларын йортларда укыдылар. Йорт хуҗалары бу гамәлне савап итеп кабул иттеләр. Өлкән яшьтәгеләр яшерен генә ураза тоттылар. Шулай итеп, нинди генә тыюлар булса да, иман буыннан-буынга күчеп барды.

Инкыйлабтан соң дин өлкәсендәге гамәлләр юкка чыккан кебек булса да, чынлыкта ул бөтенләйгә туктап калмады. Ә туксанынчы еллардан соң шактый зур үсеш алды. Мәчетләр, мәдрәсәләр төзелде. Халык бүген дә иманлы булырга, дини белем алырга тырыша, хәләл яшәү рәвешен алга сөрә.

:: Туксанынчы елларда һәр авылда диярлек мәчетләр төзелә башлады. Хәзер инде иман йорты булмаган авылны күз алдына китерү дә кыен.

– Мәчетләр төзелүнең бер үзенчәлегенә игътибар итик әле. Алар барысы да халык акчасына яки берәр мөселман кешесенең инициативасы белән төзелә. Бу бит – халыкның иманга омтылуы дигән сүз. Гомумән, мәчет-мәдрәсәләр төзергә дәүләт акчасы тотылмый. «Кол Шәриф» мәчетен генә искә төшерик. Үз өлешен кертергә теләүчеләр язылган исемлек очсыз-кырыйсыз. Ә авылларда? Беркем дә җитәкчеләр янына бил бөгеп баргандыр дип уйламыйм. Сүз дә юк, мәчет төзелешенә хакимият ярдәм күрсәткән урыннар да бар. Әмма алар бу эшкә ирекле төстә кушыла дип уйлыйм. Димәк, мәчет төзү ул – халык теләге.

:: Ислам дине кабул ителгән чорга әйләнеп кайтыйк әле. Болгар халкының әхлакый, мәдәни яктан формалашуына, берләшүенә ул ничек тәэсир иткән? Икътисад өлкәсенә нинди яңалыклар китергән?

– Идел Болгарстаны дәүләт буларак зур үсеш алган, ныгыган. Тарихчыларның тикшеренү эшләренә караганда, 922 елдан соң әби-бабаларыбызга икътисадны үстерергә, дипломатик мөнәсәбәтләрне, сәүдә эшен көйләргә мөмкинлек туган. Шулай да, иң мөһиме, ислам дине татарларның рухи культурасын баеткан. Гасырлар буена әлеге байлык халык мәнфәгатьләре өчен хезмәт итәргә, көрәш кырларында ватанны якларга, котмәгәндә килеп төшкән кайгыларны кичерергә, сөенечләр белән бүлешергә ярдәм иткән. Иң беренче чиратта ислам татар халкын милләт булып яшәткән, телебезне саклап калган.

:: Бу җәһәттән дин өлкәсендә хезмәт итүче татар галимнәре гасырлар буена төп көч булгандыр дип уйлыйк. Искә алыйк әле. Кемнәр алар? Ислам динен таратуда аларның роле нинди булган?

– Шиһабетдин Мәрҗани, Галимҗан Баруди, Габдрәхим Утыз Имәни, Габденнасыйр Курсави, Мөхәммәт Мурад Рәмзи, Ризаэддин Фәхретдин, Ялчыгол кебек галимнәребез халыкны агарту эшенә бетмәстөкәнмәс өлеш кертә. Гомумән алганда, татарның дини мәктәпләре Россиядә генә түгел, хәтта дөньяда иң көчлеләрдән саналган. Борынгы язмалардан күренгәнчә, алар традициондиннe алга сөргәннәр, кирәкмәгән яңалыклар кертеп, халыкның башын бутамаганнар. Татар диненең бу мирасы төрле милләт һәм төрле дин тотучы кешеләрнең дус һәм тату булып яшәүләренә нигез булып тора.

:: Төрле дин конфессияләре турында сөйләгәндә, гадәттә, Татарстанны үрнәк итеп куялар. Без моңа ничек ирештек?

– Ислам сүзе тынычлык дигәнне аңлата. Димәк, ул – тынычлык иңдерүче дин. Аны тагын матурлык, гаделлек, киң күңеллелек кебек сүзләр белән сыйфатлап булыр иде. Минемчә, ислам дине турында сөйләгәндә бары тик Татарстанны гына күздә тотарга кирәкми. Бу – беренчедән. Икенчедән, мондый мөнәсәбәтләр бер яклы гына була алмый. Димәк, без барыбыз да, ягъни барлык конфессияләр дә шуңа омтылабыз. Җәмгыятьтә мондый культура халыкның яшәү рәвешен яхшырта, икътисадны үстерергә ярдәм итә. Без Татарстанда бергәләп шул юлны сайладык та инде. Бу – көндәлек эш. Җыелышта ниндидер карарлар чыгарып кына моңа һич тә ирешеп булмый. Мәдәният өлкәсендәме, спорттамы, мәгариф өлкәсендәме, хәйрия эшләрендәме – бар җирдә дә катнашу мөһим. Яшьләр, балалар янында бигрәк тә. Бәйрәмгә әзерлек эшләре вакытында да без бу хакта бер генә минутка да онытмадык.

:: Әзерлек эшләре турында сөйләшкәндә иң мөһим чаралар исемлеге белән укучыларны да таныштырган идек. Шул уңайдан бигрәк тә Җәмигъ мәчетенең килачәге, кулдан язылган Коръән һәм аның типографиядә нәшер ителәчәк яңа басмасы белән кызыксынучылар бар. Бу җәһәттән нилар эшләнде һәм ни эшләргә җыеналар?

– Казан – ислам дөньясының төньяк башкаласы, мөселман илләре өчен капка булып хезмәт итә. Башкалада «Россия – ислам дөньясы» төркеме оештырган халыкара чаралар уза. Димәк, киләчәктә башкалабызны күп кеше сыйдырышлы җәмигъ мәчетеннән башка күзаллау авыр булачак. Өстәвенә мәчет бит ул намаз уку урыны гына түгел, без яшьләрне, балаларны җәлеп итәргә, социаль яктан әһәмияте булган төрле чаралар үткәрергә хыялланабыз. Шулай ук музей, төрле күргәзмәләр оештыру өчен дә аерым урыннар билгеләнер дип көтелә.

Кулдан язылган Коръәнгә килгәндә исә, ул каллиграфия сәнгате буларак дөнья күрәчәк. Гарәп хәрефләрен язу кагыйдәләрен өйрәнүче фәнне торгызуга беренче адым булачак. Бүгенгә язма Коръәннең бер өлеше эшләнгән иде. Аны язу дәвам итә.

Шулай ук типография ысулы белән дә яңа басма нәшер ителәчәк. Тарихка күз салсак, беренче Коръән 1803 елда Казанда басыла. Ул «Казан басмасы» дип атала. Үзенчәлекле хәрефләр куллану беренче басманы бөтен дөнья буйлап таратырга мөмкинлек бирә. Татарстан Диния нәзарәте аны берничә тапкыр кабат бастырды. Әмма басмаханә хәрефләренең сыйфаты начаррак иде. Узган ел ахырында «Казан басмасы» дип аталган яңа хәрефләр эшләнде. Хәзер инде тарихи йөзен саклаган символларны да компьютер аша кертергә була. Шул рәвешле без «Казан басмасы»ның яңасын әзерлибез. Форсаттан файдаланып шуны да әйтик: Татарстан Диния нәзарәтенең «Хозур» нәшрияты бүген Россиядә дини медиахолдинглар арасында иң уңышлылардан санала. Монда китаплар гына түгел, бәлки вакытлы басмалар да нәшер ителә. «Хозур ТВ» каналы, «Азан» радиосы, берничә интернет-проект эшләп килә. Иң соңгы яңалыкларның берсе – беренче татар онлайн мәдрәсәсе. Әйтергә кирәк, ул шундый да кирәкле гамәл булып чыкты. Бүген бу порталда без Россиядән генә түгел, ә бәлки Европадан, Америкадан, Австралиядән, Кытайдан һәм башка бик күп илләрдән кулланучылар барлыгын күрәбез. Татарстанда ислам белеме бирү системасы бик алга киткән. Читтән торып эшләүче программалар да бар, халыкка лекцияләр дә укыла. Республикада бүген 8 мәдрәсә, мәчетләр каршында 700дән артык курс бар. Ике югары уку йорты һәм Болгар ислам академиясе эшләп килә. Димәк, бу – яхшы билгечләр дә әзерләнә дигән сүз.

:: Ничек уйлыйсыз, бүгенге шартларда ислам диненең миссиясе нинди? Гореф-гадәтләрне, телне, халыкны саклап калуда аның роле ни дәрәҗәдә?

– Россиядә ислам тарихына күз салсак, дин әһелләре халыкны берләштерү мәсьәләсендә иң төп рольләрнең берсен уйнаган. Татарларның гасырлар буена Көнчыгыш һәм Көнбатыш, Азия һәм Европа чигендә яшәүләре башка дин вәкилләре белән тынычлыкта, татулыкта калуны тәэмин иткән. Агарту юлында армый-талмый эшләгән татар халкының бөек уллары заманында мәдрәсәдә белем алганнар. XX гасыр башында да дин әһелләре татар тормышында алгы сафта булганнар. Хәтта «Иттифак-әл-мөслимин» дип аталган партияләре булып, сәяси өлкәдә дә үз фикерләрен җиткерә алганнар. Бүген исә берннди каршылыклар юк. Димәк, төп бурычыбыз – халыкка хезмәт итү юлыннан тайпылмау.

Әңгәмәдәш – Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

23 май | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН
05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 15.30 «ТУЗГАН ТОРАКТАН КҮЧКӘНДӘ» 12+
10.00, 23.30 «УСЛОВИЯ КОНТРАКТА 2» 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
11.30 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 22.40 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 12+
14.45 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Уймак» һәм «Сәйлән» 0+
16.30 «Татарлар» 12+
17.00 «Мин» 12+
17.30 «Татарстан без коррупции» 12+
19.00, 20.00, 01.10 «Таяну ноктасы» 16+
21.00 «Заман көзгесе» 6+
22.00 «Вызов 112» 16+
22.10 «Реальная экономика» 12+
00.20 «Рыцари вечности». Пушкин. «Капитанская дочка» 12+
00.35 «Фолиант в столетнем переплете». Цельногравированные издания 6+
00.50 «Не от мира сего...» 12+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Җырлыйк әле!» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00, 13.00, 01.05 «Манзара» 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30 «Ватандашлар» 6+
12.05 «Таҗдай кояш нурлары». Татарстанның халык артисты Ринат Таҗетдинов турында телеочерк 6+
15.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
19.10, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
02.50 «Караоке татарча» 6+

1 КАНАЛ
05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.40 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. Олег Меньшиков, Алексей Серебряков. «ВАША ЧЕСТЬ» (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 «АнтиФейк» 16+
00.25 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1
05.00, 09.30 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА» 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
01.00 «ЗЕМСКИЙ ДОКТОР» 12+
02.45 «ВЕРСИЯ» 16+

МАТЧ ТВ
06.00, 08.55, 12.30, 15.05 Новости
06.05, 22.40 Все на Матч! Прямой эфир
09.00, 12.35 Специальный репортаж 12+
09.20 Хоккей. Чемпионат мира. Швеция – Норвегия. Трансляция из Финляндии 0+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
12.55 Хоккей. Чемпионат мира. Швейцария – Франция. Трансляция из Финляндии 0+
15.10 «Громко». Прямой эфир
16.15 Хоккей. Чемпионат мира. США – Чехия. Прямая трансляция из Финляндии
18.40 Гандбол. Чемпионат России «Олимпбет-Суперлига». Женщины. Финал. Прямая трансляция
20.15 Хоккей. Чемпионат мира. Канада – Дания. Прямая трансляция из Финляндии
23.25 Тотальный футбол 12+
23.55 Хоккей. Чемпионат мира. Казахстан – Италия. Трансляция из Финляндии 0+
02.00 Пляжный волейбол. BetBoom Чемпионат России. Женщины. Финал. Трансляция из Анапы 0+
02.55 Новости 0+
03.00 Пляжный волейбол. BetBoom Чемпионат России. Мужчины. Финал. Трансляция из Анапы 0+
03.55 Танцевальный спорт. Латиноамериканские танцы. «Кубок Кремля – Гордость России!» Трансляция из Москвы 0+

НТВ
04.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.00 Сегодня
08.25, 10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ» (S) 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 «ВСПЫШКА» (S) 16+
23.25 «ПЁС» (S) 16+
02.50 Их нравы 0+
03.10 «ШАМАН» (S) 16+

ДОМАШНИЙ
06.30 «Чудотворица» 16+
06.55 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.00 «Давай разведёмся!» 16+
10.00 «Тест на отцовство» 16+
12.15 «Понять. Простить» 16+
13.20 «Порча». «О чём молчит немой» 16+
13.50 «Знахарка» 16+
14.25 «Верну любимого» 16+
15.00 «ВОЗВРАЩЕНИЕ К СЕБЕ» 16+
19.00 «ЛЮБОВЬ С ЗАКРЫТЫМИ ГЛАЗАМИ» 16+
23.00 «ЖЕНСКИЙ ДОКТОР 3» 16+
01.00 «Понять. Простить» 16+
01.50 «Порча» 16+
02.15 «Знахарка» 16+
02.40 «Верну любимого» 16+
03.05 «Тест на отцовство» 16+
04.45 «Давай разведёмся!» 16+
05.40 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА
05.20 «НЕ ЗАБЫВАЙ» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.30, 13.25, 18.45 «Специальный репортаж» 16+
09.50 «ПРИКЛЮЧЕНИЯ ШЕРЛОКА ХОЛМСА И ДОКТОРА ВАТСОНА». «СОБАКА БАСКЕРВИЛЕЙ» 12+
11.20, 19.00 «Открытый эфир» 16+
13.50, 14.05 «Легенды госбезопасности. Самый главный бой». Док. фильм 16+
14.00 Военные новости 16+
14.40 «НА РУБЕЖЕ. ОТВЕТНЫЙ УДАР» 16+
22.00 «Между тем» 12+
22.25 «Загадки века». Док. сериал. «Денацификация Германии» 12+
23.15 «БЫЛО. ЕСТЬ. БУДЕТ» 16+
01.20 «НЕ ХЛЕБОМ ЕДИНЫМ» 12+
03.35 «Калашников». Док. фильм 12+
04.00 «ВНИМАНИЕ, ГОВОРИТ МОСКВА!» 16+

24 май | Сишәмбе

ТАТАРСТАН
05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «ТУЗГАН ТОРАКТАН КҮЧКӘНДӘ» 12+
10.00, 23.00 «УСЛОВИЯ КОНТРАКТА 2» 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 12+
11.15 «Память сердца» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
13.00 «Родная земля» 12+
13.30 «Юлчы» 6+
14.00 «Путь» 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Уймак» һәм «Сәйлән» 0+
16.00 «Ватандашлар» 12+
18.00 «Казаннан – казанга» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
21.00 «Ватандашлар» 12+
00.00 «Видеоспорт» 12+
00.25 «Соотечественники». Живи 1000 лет. Риза Фахретдинов. 1 серия 12+
00.50 «Рыцари вечности» 12+
01.05 «Фолиант в столетнем переплете». Редкое издание. Бракосочетание царя Михаила Федоровича 12+
01.30 «Таяну ноктасы» 16+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Ком сәгате» 12+
05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00, 13.00, 01.05 «Манзара» 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Җырлыйк әле!» 6+
09.40 «Родная земля» 12+
10.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05 «Йөрәктән – йөрәккә». Нәҗип Җиһанов турында телеочерк 6+
15.30 «Тамчы-шоу» 6+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
19.10, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.30 «Ватандашлар». Индус Таһиров 6+
02.50 «Караоке татарча» 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ
05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.40 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. «ВАША ЧЕСТЬ» (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 «АнтиФейк» 16+
00.25 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1
05.00, 09.30 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. «ЕЛИЗАВЕТА» 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
01.00 Ольга Будина. «ЗЕМСКИЙ ДОКТОР» 12+
02.45 «ВЕРСИЯ» 16+

МАТЧ ТВ
06.00, 08.55, 19.15 Новости
06.05, 15.40, 18.40, 22.40 Все на Матч! Прямой эфир
09.00, 14.40 Специальный репортаж 12+
09.20 Хоккей. Чемпионат мира. США – Чехия. Трансляция из Финляндии 0+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
12.15 Хоккей. Чемпионат мира. Германия – Швейцария. Прямая трансляция из Финляндии
15.00 Футбол. Тинькофф Российская Премьер-лига. Обзор 0+
16.15 Хоккей. Чемпионат мира. США – Норвегия. Прямая трансляция из Финляндии
19.20 Смешанные единоборства. UFC. Холли Холм против Кетлин Виеры. Трансляция из США 16+
20.15 Хоккей. Чемпионат мира. Финляндия – Чехия. Прямая трансляция из Финляндии
23.25 Хоккей. Чемпионат мира. Швеция – Латвия. Трансляция из Финляндии 0+
01.35 Баскетбол. Единая лига ВТБ. Матч за 3-е место. «Локомотив-Кубань» (Краснодар) – УНИКС (Казань) 0+
03.20 Новости 0+
03.25 Футбол. Кубок Либертадорес. Прямая трансляция
05.30 «Правила игры» 12+

НТВ
04.45 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.00 Сегодня
08.25, 10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ» (S) 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 «ВСПЫШКА» (S) 16+
23.25 «ПЁС» (S) 16+
02.50 «АГЕНТСТВО СКРЫТЫХ КАМЕР» (S) 16+
03.20 «ШАМАН» (S) 16+

ДОМАШНИЙ
06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.05 «Давай разведёмся!» 16+
10.05 «Тест на отцовство» 16+
12.20 «Понять. Простить» 16+
13.25 «Порча». «Виртуальный ребёнок» 16+
13.55 «Знахарка» 16+
14.30 «Верну любимого» 16+
15.05 «ПРОБУЖДЕНИЕ ЛЮБВИ» 16+
19.00 «УСПЕТЬ ВСЁ ИСПРАВИТЬ» 16+
23.00 «ЖЕНСКИЙ ДОКТОР 3» 16+
01.00 «Понять. Простить» 16+
01.50 «Порча» 16+
02.15 «Знахарка» 16+
02.40 «Верну любимого» 16+
03.05 «Тест на отцовство» 16+
04.45 «Давай разведёмся!» 16+
05.40 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА
05.25 «ВНИМАНИЕ, ГОВОРИТ МОСКВА!» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.25, 18.45 «Специальный репортаж» 16+
09.45 «ПРИКЛЮЧЕНИЯ ШЕРЛОКА ХОЛМСА И ДОКТОРА ВАТСОНА». «СОБАКА БАСКЕРВИЛЕЙ» 12+
11.20, 19.00 «Открытый эфир» 16+
13.25 «Не факт!» 12+
14.00 Военные новости 16+
14.05 «МОЯ ГРАНИЦА» 16+
22.00 «Между тем» 12+
22.25 «Улика из прошлого». «Заживо сожженные. Тайна Одесской трагедии» 16+
23.15 «ПРИКЛЮЧЕНИЯ ШЕРЛОКА ХОЛМСА И ДОКТОРА ВАТСОНА». «СОБАКА БАСКЕРВИЛЕЙ» 12+
00.35 «Восход Победы». Док. сериал 12+
03.40 «МОЯ ГРАНИЦА» 16+

ЙОЛДЫЗНАМӘ 23–29 МАЙ

КУЧКАР (21.03 – 20.04)
Ниндидер бер яңа мәгълүматтан һәм ышандыру осталыгыннан файдаланып, кечкенә, әмма бик күркәм уңышка ирешерсез.

ҮГЕЗБОЗАУ (21.04 – 20.05)
Озын еллардан соң әле бер генә атна узуга карамастан, эш турында бик үк уйлыйсы килмәс. Хәер, бу халәт артык озакка да сузылмас: инде пәнҗешәмбе тирәсендә үк бер эшне чын профессионалларча башкарып, җитәкчегезнең мактавына лаек булырсыз.

ИГЕЗӘКЛӘР (21.05 – 21.06)
Атна башында бер мәгълүмат уйларыгызны чуалтып җибәрергә мөмкин. Борчыласы юк: болай килеп чыгуы сезнең өчен әйбәтрәк тә булачак әле. Ял көннәренә таба зур гына максатыгызга ирешә башлавыгызны тоеп сөенерсез.

КЫСЛА (22.06 – 22.07)
Килеп туган хәлләр планнарыгызга берaз үзгәреш кертер. Ләкин ахырда барысы да үзегез көткәннән дә яхшырак килеп чыгар. Эш урыныңда матур бер гамәлегез акыллы гына түгел, рухи яктан көчле булуыгызны да күрсәтер.

АРЫСЛАН (23.07 – 23.08)
Бу атнада сан артыннан кумыйча, күбрәк сыйфат ягын карарга туры килер. Аннан килеп, хезмәттәшләрегезнең сүзләренә колак салырга кирәк булыр. Ник дигәндә, эшкә һәм үз дөньягызга чумып, кайбер әйберләрне күрми калуыгыз бар.

КЫЗ (24.08 – 22.09)
Килеп туган юк-бар проблемаларны усаланып түгел, бәлки акыллы, түземле генә хәл итәргә тырышыгыз. Вак-төяккә игътибарлы булыгыз – алар сезгә кызыклы әйберләр ачачак.

ҮЛЧӘҮ (23.09 – 23.10)
Мөһим документны югалту яки хата җибәрү куркынычы бар. Атна уртасында керемгә кагылышлы әйбәт кенә яңалыклар ишетерсез. Дустыгыз чишкән бер сердән каушабрак калырсыз.

ЧАЯН (24.10 – 22.11)
Уңышлы, бәхетле һәм бәрәкәтле чор. Тормышыгыз бик көйле, эшләрегез моңарчы күрелмәгән дәрәҗәдә җайлы барачак. Күптәннән көтелгән бер тәкъдим (өстәмә керем чыганагына бәйле булыр, ахры) ишетеп сөенерсез.

УКЧЫ (23.11 – 21.12)
Дусларыгыз белән мөнәсәбәтләр бозылырга мөмкин. Сәбәбеме? Бурычны түли алмыйча йөрү...

КӘҖӘМӨГЕЗ (22.12 – 20.01)
Тирәгездәгеләр белән итагатьлерәк мөгамәләдә булырга яисә әлегә аралашмыйча торырга тырышыгыз. Атна ахырында тормышыгызга ямь өстәрдәй вакыйга көтегез.

СУКОЯР (21.01 – 19.02)
Авызыгызны бер тапкыр ачканчы, җиде кат уйлагыз. Ә менә атна ахырында эштә дәрәҗәгезне үстереп җибәрердәй хәлләр килеп чыгар.

БАЛЫК (20.02 – 20.03)
Сабырлык кирәк. Кимчелек кемдә дә бар. Шулай ук –сездә дә. Кемнедер яшәргә өйрәтү низагка китерергә мөмкин. Тынычрак булыгыз.

БЕЛДЕРҮ

ИЗВЕЩЕНИЯ О ПРОВЕДЕНИИ СОБРАНИЯ ПО СОГЛАСОВАНИЮ МЕСТОПОЛОЖЕНИЯ ГРАНИЦ ЗЕМЕЛЬНЫХ УЧАСТКОВ

Кадастровым инженером Садыковым Ф.Р., являющимся членом Саморегулируемой организации «Ассоциация кадастровых инженеров «Поволжья» (уникальный реестровый номер кадастрового инженера в реестре членов СРО КИ: №1467, Республика Татарстан, Новошешминский район, с. Новошешминск, ул. Ленина, д. 36, кв. 4; sfkadastr@gmail.com, тел: +7 (908) 349-94-54, номер регистрации в государственном реестре лиц, осуществляющих кадастровую деятельность: № 33593), выполняются кадастровые работы в отношении земельного участка с кадастровым номером 16:50:050119:11, расположенного по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, Советский район, ул. Сергея Лазо, дом 14.

Заказчиком кадастровых работ является Зиятдинова Чулпан Магалимовна (адрес регистрации: Республика Татарстан, г. Казань, Советский район, ул. Сергея Лазо, дом 14).

Собрание по поводу согласования местоположения границы состоится по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Спартаковская, д. 88б 23 июня 2022 г. в 10 час. 00 мин.

С проектом межевого плана земельного участка можно ознакомиться по адресу проведения собрания у кадастрового инженера.

Требования о проведении согласования местоположения границ земельных участков на местности принимаются с 21 мая 2022 г. по 21 июня 2022 г., обоснованные возражения о местоположении границ земельных участков после ознакомления с проектом межевого плана принимаются с 21 мая 2022 г. по 21 июня 2022 г. по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Спартаковская, дом 88б.

Смежные земельные участки, с правообладателями которых, требуется согласовать местоположение границы, расположенные по адресу:

1) Республика Татарстан, г. Казань, район Советский, ул. Сергея Лазо, д. 16, кадастровый номер 16:50:050119:12;
2) Республика Татарстан, г. Казань, район Советский, ул. Сергея Лазо, д. 12, кадастровый номер 16:50:050119:1.
– иные заинтересованные лица.

При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы о правах на земельный участок (оригинал) (часть 12 статьи 39, часть 2 статьи 40 Федерального закона от 24 июля 2007 г. № 221-ФЗ «О кадастровой деятельности»).

Кадастровым инженером Хабибуллиным Ильдаром Ибрагимовичем (номер квалификационного аттестата кадастрового инженера: 16-14-724, адрес: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Тихомирнова, д. 11, 420107, ildarkhabib@mail.ru, тел.: +79272414666, номер регистрации в государственном реестре лиц, осуществляемых кадастровую деятельность 31944) проводятся кадастровые работы в отношении земельного участка, расположенного по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, Ново-Савиновский район, ул. Адоратского, д. 35б с кадастровым номером 16:50:110801:108.

Заказчиком кадастровых работ является Хисамутдинов Гарафутдин Минегазизович (контактная информация: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Тихомирнова, д. 11, тел.: +79272414666).

Собрание заинтересованных лиц по поводу согласования местоположения границ состоится по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Тихомирнова, д. 11 21 июня 2022 г. в 10.00 ч.

С проектом межевого плана можно ознакомиться по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Тихомирнова, д. 11.

Требования о проведении согласования местоположения границ земельных участков на местности принимаются с 20 мая 2022 г. по 20 июня 2022 г., обоснованные возражения о местоположении границ земельных участков после ознакомления с проектом межевого плана принимаются с 20 мая 2022 г. по 20 июня 2022 г. по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Тихомирнова, д. 11.

Смежные земельные участки, с правообладателями которых требуется согласовать местоположение границ: 16:50:110801:9065 (Республика Татарстан, г. Казань, Ново-Савиновский район, ул. Адоратского, д. 43).

При проведении согласования местоположения границ при себе иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы о правах на земельный участок (часть 12 статьи 39, часть 2 статьи 40 Федерального закона от 24 июля 2007 г. № 221-ФЗ «О кадастровой деятельности»).

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ГИПЕРТОНИЯ СУКЫЙРАТА

Татарстанда яшәүче 400 меңнән артык кеше югары кан басымыннан интегә. Чынлыкта республикада артериаль гипертония диагнозы белән яшәүчеләр саны күпкә артык, дип фаразлый белгечләр. Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының баш кардиологы, Казан дәүләт медицина университетының кардиология кафедрасы мөдире Альберт Галәвич, Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының штаттан тыш баш кардиологы Зөлфия Ким һәм Идел буе федераль округының штаттан тыш баш балалар кардиологы Динара Садыйкова журналистлар белән очрашуда әнә шул хакта сөйләде. Белгечләрнең фикер-киңәшләрен укучыларыбыз игътибарына да тәкъдим итәбез.

pixabay.com

◆Гипертония – иң киң таралган авыруларның берсе. Бүген Татарстанда югары кан басымыннан интеккән 400 мең кеше исәптә тора. Әмма, чынлыкта, бу саннар артыграк булырга тиеш. Ник дигәндә, күпләр югары кан басымы белән яшәвен белмәскә дә мөмкин. Баш авырткач, дару эчәләр дә шуның белән тынычланалар. Чынлыкта ул гипертония булып чыга. Юкка гына бу чирне «мыштым үтерүче» дип атамыйлар инде.

◆Кан басымы, иң беренче чиратта, стресс аркасында күтәрелә. Коронавирус котырган пандемия чорында мондый киеренке халәттә яшәүчеләр саны бермә-бер артты. Әйләнә-тирәдә бөтен кешенең авыруы, урамга чыкканда битлек, пирчәткә кияргә кирәк дип тукып торулар барысы да кешенең психикасына тискәре йогынты ясый. Шуңа күрә пандемия чорында дөнья күләмендә югары кан басымыннан интегүчеләр саны 10–15 процентка арткан. Бу – рәсми дәлилләнгән сан.

◆Кан басымы 140/90нан югарырак булса, чаң сугарга җирлек бар. Өске күрсәткечләр 130 миллиметрдан югарырак булганда ук кичекмәстән табибка күренергә кирәк. Гипертонияле кешегә кан басымының 110 миллиметрдан түбәнрәк төшүе дә куркыныч.

◆Бүген югары кан басымыннан интегүченең кыскача портреты түбәндәгедән гыйбарәт: ул – гәүдә авырлыгы нормадан арткан, тозлы ашарга яратучы, аз хәрәкәтләнеп, даими рәвештә стресс халәтендә яшәүче, тәмәке тарту кебек начар гадәте булган 35 яшьтән өлкәнрәк кеше.

◆Кан басымы югары булган кешенең башы авырта, тыны кысыла, башы әйләнә, күз аллары караңгылана, ул начар йоклый, ярсуганга әйләнә, даими рәвештә хәлсезлек сизә. Бу билгеләрнең берсен дә игътибарсыз калдырырга ярамый.

◆Балалар арасында да югары кан басымыннан җәфаланучылар шактый. Аларның бер ише анадан ук гипертония белән туа, икенче берләре исә үсмерлек чорына кергәч, югары кан басымыннан тилмерә. Югары кан басымы балаларда бернинди билгеләрсез генә дә узарга мөмкин. Күп очракта, үлчәп карагач кына, аның югары икәнлеге ачыклана.

◆Балаларның югары кан басымыннан интегүенә, нигездә, шул ук артык авырлык, хәрәкәт җитмәү, фастфуд һәм газлы эчемлекләр белән мавыгу сәбәпче. Гаджетлардан аерыла алмаулары да тискәре йогынты ясый. Гаджет экраныннан сирпелгән зәңгәр ут үзәк нерв системасын ярсыта. Шул сәбәпле бала начар йоклый башлый. Шуңа күрә йокларга ятарга ике сәгать кала, компьютер һәм телевизорларны сүндереп, гаджетларны читкә алып куярга кирәк. Баш авырту, начар йоклау кебек билгеләр күзәтелсә, баланың кан басымы югары дип шикләнергә җирлек бар.

◆Гипертония инсульт, инфаркт куркынычын арттыра. Кан басымының югары булуы йөрәккә, кан тамырлары, бөер, баш миенә дә тискәре йогынты ясый. Гипертония аркасында кеше сукыраерга да мөмкин.

◆Күпләр югары кан басымыннан котылу өчен, хастаханәгә ятып, система алырга кирәк дип саный. Әмма организмга тамчылап кергән дару, киресенчә, кан басымын күтәрә генә.

◆Гипертонияне туганың, күршең киңәш иткән дару-алымнар белән дәваларга ярамый. Һәр организмның – үз үзенчәлеге. Берәүгә килешкән дару икенче бер кешегә тискәре йогынты ясарга мөмкин. Югары кан басымы вакытында эчелә торган дарулар тиз арада гына файда китерми. Аларның файдасы дару эчкән көннән соң өч ай эчендә сизеләчәк.

ЮГАРЫ КАН БАСЫМЫННАН ИНТЕККӘН КЕШЕГӘ КИҢӘШЛӘР



➤Сезгә гипертония диагнозы куйсалар, үзегезнең кардиолог яки участок терапевтына исәпкә басарга кирәк.

➤Кан басымының иртәнге һәм кичке күрсәткечләрен язып бару өчен, махсус көндәлек башлагыз.

➤Организмыгыздагы үзгәрешләргә игътибарлы булыгыз. Кан басымыгыз кайсы очракларда күтәрелә? Шуларны ачыклап, киләчәктә андый хәлләрне читләп узарга тырышыгыз.

➤Көн саен 30–40 минут саф һавада йөрегез. Кан басымы югары булганда хәрәкәттән дә яхшырак дәва юк!

➤Ашаган ризык та игътибардан читтә калмасын. Гипертониядән интеккән кешеләргә чипсы, газлы эчемлекләрдән тыелып тору хәерле.

➤Тынычлык саклагыз. Стресс – кан басымының дошманы.

Үзем сынадым

Кан басымын төшерә

Кан басымы күтәрелгәндә, бер эчемлекнең файдасын күрәм. Аны һәркем әзерли ала. Аны ясау өчен 1:1:1 исәбендә кара миләш, балан һәм бал кирәк. Аларның барысын бергә кушып, пыяла банкага салып, капрон капкач каплап, суыткычка алып куярга кирәк. Кан басымы күтәрелгәндә, шушы төнәтмәне 1 аш кашыгы алып кабам да 1 стакан җылы су белән эчәм.

Разия ФӘЛАХОВА. Казан

Эч катудан булыша

Алма. Олы йомышны җайга салу өчен, клетчаткага бай ризыклар ашарга киңәш ителә. Алмада исә эрүче клетчатканың аерым төре – пектин бар. Ул эчне йомшартырга ярдәм итә дә инде.

Караҗимеш. Ул табигый эч йомшарту чарасы санала. Анда, клетчаткадан тыш, А витамины һәм калий күп. Моннан тыш, караҗимеш составында кеше организмы тарафыннан авыр үзләштерелүче сорбит бар. Әнә шул эч кату очракларында эчәкләрне бушатырга ярдәмгә килә дә инде.

Киви. Бу экзотик җимеш – клетчатка чыганагы. Ул ашкайнату трактында хәрәкәт барлыкка китерә. Кивины коктейльләргә кушарга, иртәнге аш белән ашарга яки аерым десерт итеп кулланырга мөмкин.

Җитен орлыгы. Аны боткаларга, йогыртка, беренче һәм икенче ашларга, коктейльләргә өстәргә киңәш ителә. Моннан тыш салатлар ясаганда җитен маен куллануны гадәткә кертегез.



Груша. Груша клетчаткага, фруктоза һәм сорбитка гаять бай. Шуның белән ул суны эчәкләргә тартып, бушануга ярдәм итә.

Ногыт борчагы. Анда эрүчән һәм эремәүчән клетчатка бар. Аларның һәркайсы эч катудан котылырга ярдәм итә.

Кефир. Бу әчкелтем ризыкта эчәклек өчен мөһим булган пробиотиклар бар. Кефирны йоклар алдыннан, бераз җитен орлыгы яки җиләк-җимеш кушып эчәргә мөмкин.

Исеңдә тот!

Алма серкәсе – дәва

Алма серкәсе – буыннар авыртуга каршы менә дигән дәвалау чарасы. Аны башка төрле дә кулланып була. Ул көчле антиоксидант буларак, организмны токсиннардан чистартырга ярдәм итә.

Ванна өчен. 1 стакан алма серкәсен 6 стакан суга салып, кулларны һәм аякларны шунда тыгып торырга. Әгәр сезне муен, җилкә тирәсендә авыртулар борчый икән, ул вакытта авырткан урынга компресс куегыз.

Уыну өчен. 2 стакан алма серкәсенә 1 аш кашыгы зәйтүн мае салып, яхшы итеп болгатырга кирәк. Шуның белән авырткан урыннарны уыгыз. Даими куллансагыз, рәхәт җиңеллек тоярсыз.

Шифалы эчемлек

3 аш кашыгы алма серкәсен 300 г суга яки теләсә нинди җимеш согына кушып болгатырга кирәк. Шуны көненә 3 тапкыр, ашар алдыннан эчеп куегыз.

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Валентина СЕМЕНОВА

МАЙ – МӘШӘКАТЬЛЕ АЙ

Теплицага, түтәлләргә утыртыласы асылда инде утыртылып бетсә дә, бакчачыларның кул кушырып утырырга вакыты юк. Нәкъ менә май ахырында җимеш агачлары һәм куаклар аерым бер игътибар-карауга мохтаҗ. Урам һавасына «чыккан» яшелчә үсентеләрен «терелтеп» җибәрүгә бәйле эшләр дә бихисап.

Шуларны истә тотып, бакчачы-блогер Эльмира ИСХАКОВАдан укучыларыбыз сорауларына җавап бирүен сорадык.

:: Бакча җиләкләрен быелтыр көздән утыртып калдырган идем. Үсентеләр, яфраклары кызарып, хәлсезләнеп утыра. Нәрсә сибеп карарга икән?

Нәҗия СӘЕТГӘРӘЕВА. Зәй районы

– Азот җитмәгәнлектән бу. Түбәндәге рецепт белән ясалган катнашма кулланып карагыз әле. Иң элек, туфрагы дымлы булсын өчен, гади су сибәсе. Аннан соң 10 литр суга 2–5 грамм бор кислотасы, 1 аш кашыгы йод, 2 грамм марганцовка һәм 2 аш кашыгы нашатырь спирты салып, катнашма ясыйсы. Һәр төпкә, яфракларына да тидереп, 1 литр чамасы катнашма сибәсе. Бу максатта 10 процентлы нашатырь спиртыннан (10 литр суга 40 мл), водород перекисе (1 литр суга 2 аш кашыгы), нитроаммофоска (10 литр суга 1 аш кашыгы), мочевинадан (10 литр суга 1 шырпы кабы) да файдаланырга мөмкин.

:: Агач-куаклар мулрак җимеш бирсен өчен язын нинди ашлама кертү әйбәтрәк? Төпләрен мүлчәләү тәртибе турында да аңлатып үтсәгез иде.

Вероника ЗАХАРОВА. Питрәч

– Иң элек агач-куакларга, шулай ук дым яратучы виктория һәм кура җиләге үсентеләренә яхшылап су сибү мөһим. Шуннан соң, дым тиз генә китмәсен өчен, төбен мүлчәләү һәм йомшарту кирәк. Мүлчә (компост, черегән агач яфраклары, салам, чапкан үлән, агач чүбе булырга мөмкин) агач-куаклар төбенә, кура җиләге рәтләре, куппеллык чәчәкләр арасына урнаштырыла. Җиләк үсентеләренә мүлчә катламын кимендә 7 см калынлыкта җәяргә кирәк. Органик мүлчә менә дигән ашлама да булып тора.

Тукландыруга килгәндә, язын үсентеләр азотка мохтаҗ. Яшь үсентеләргә азот, фосфор һәм калийдан торган комплекслы ашлама кертү әйбәт. Бу максатта көлдән дә файдаланырга мөмкин (яшь үсентеләргә 10–150 грамм, зурларына – 150–200әр грамм исәбеннән). Моның өчен агач төбенә тирән итмичә генә буразналар ясап, ашлама салырга кирәк.

:: Груша агачы бер-ике еллап утырды да, җимеш бирергә дә өлгермичә, корыды...

Ирек ГЫЙЛАҖИЕВ. Балтач районы

– Иң элек сорты безнең климатка яраклы булып чыкмаска мөмкин. Безнең якларда, әйтик, Чижовская, Яковлевская, Десертная Россошанская, Августовская роса, Дюшес летний кебек сортлар әйбәт үсә. Груша – бик нәзберек агач. Аңа суны вакытында сибеп торырга кирәк. Туфрагы артык кибеп китсә, тамырларына зыян киләчәк. Шул ук вакытта агач грунт суларын яратмый. Шуңа күрә урыныңның бик уйлап сайлап алынган булуы мөһим. Уйсурак җиргә утыртылса, яфраклары корый башлый. Турыдан-туры төшкән кояш нурлары исә яфракларын көйдерә. Шуңа күрә аңа 5 сәгать чамасы гына кояш төшә торган урынны сайлап алу таләп ителә. Юкса, яфракларына зыян килеп кенә калмый, ул җимеш тә бирмәскә мөмкин. Шунысы да бик мөһим: утыртканда, үсентенең тамыр муентыгы (тамыры башланган урын) җир өслегеннән күп тә түгел, аз да түгел – 5–6 см чыгып калырга тиеш. Әлбәттә, агачны вакытында тукландыру һәм корткычлардан саклау (әйтик, кәүсәсен агартып) да бик кирәк.

:: Тузганактан үлән бетенә һәм күбәләк кортына каршы төнәтмә ясау ысулын аңлатып үтмәссезме?

Дания НУРЕТДИНОВА. Казан

– Бакчачылар тузганактан тизрәк котылу ягын караса да, чынында ул – файдалы үсемлек. Борынгы әбиләрнең кыяр түтәле янында бернечә тузганакны йолкымыйча калдырулары беләсезме икән? Моның сәбәбен галимнәр болайрак аңлата. Чәчәк ату чорында үсемлек этилен эшләп чыгара, ә бу кыярның тизрәк өлгерүенә китерә. Төнәтмә ясау ысулына килгәндә, 200 грамм тамырын (яки 400 грамм яфрагын), ваклап, 40 градуслы 10 литр суда 2 сәгать төнәтәбез. Шуннан, сөзеп, 30 грамм уылган кер сабыны өстибез. Агач-куакларга чәчәк атканнан соң һәм 10–15 көн узгач бөркибез. Төнәтмәне кәбестәгә, башка яшелчәләргә дә сибәргә мөмкин.

:: Теплицада помидор үсентеләре «чирләп» утыра. Аларны ничек «терелтеп» булыр икән?

Нурсәнә ГАРИПОВА. Балык Бистәсе

– Теплицада помидор үсентеләренең «чирләве» көннәрнең суык торуына бәйле бу. Инструкциясендә язылганча, фитоспорин эремәсен сибеп карасагыз була. Җирен дә шуның белән эшкәртегез. Яисә 10 литр суга 10–20 грамм исәбеннән калий селитрасы эремәсе ясап сибегез.

Аш-су

Сиринә НУРГАЛИЕВА рецептлары

«ЯЗГЫ» ЙОМЫРКА КАЛҖАСЫ

Кирәк булачак: *100 грамм яшь кычыткан, 1 яшь сарымсак, 3 йомырка, 1 башлы суган, 100 мл сөт, 50 г атланмай.*

Кычытканны башта, чакмасын өчен, кайнап торган суга салып, 2 минут пешеклибез. Суын түгеп сыытабыз һәм сабагы белән бергә ваклап турыйбыз. Сарымсакны сабагы белән – бөҗралап, суганны шакмаклап турыйбыз. Табада атланмай эретеп, яшелчәне алтынсу төскә кергәнче кыздырабыз. Аерым савытта сөт белән йомырканы яхшылап болгатабыз һәм табадагы суган белән сарымсак өстенә салабыз. Кычыткан өстәп, таба капкачын ябабыз һәм калҗаны әледәнәле чәнечке белән төрткәләп, 10 минут пешерәбез. Табынга яшелчә белән куябыз.

КЫЧЫТКАН ҺӘМ КУЗГАЛАК АШЫ

Кирәк булачак: *1әр бәйләм кычыткан (учка сыярлык) һәм кузгалак, 4әр сабак петрушка һәм укроп, 4 йомырка, 4 бытбылдык йомыркасы (булмаса да ярый), 5 бәрәңге, 1 баш суган, 2 кишер, бер чеметем тоз, борыч, кыздыру өчен үсемлек мае, 2 литр шулпа (су).*

Суганны шакмаклап турыйбыз, кишерне угыч аша чыгарабыз да, алтынсу төскә кергәнче, майда кыздырабыз. Йомырканы пешерәбез. Суынгач, шакмаклап турыйбыз. Яшел тәмләткечләрне, шул исәптән кузгалакны юабыз, кычытканны кайнап торган суда 1–2 минут пешеклибез. Барысын да ваклап турыйбыз. Кайнап торган шулпага (суга) бәрәңге турап салабыз. Кайнап чыккач, кыздырылган яшелчәне һәм йомырка өстибез. Бәрәңгесе пешкәч, яшел тәмләткечләр һәм кычыткан салабыз, тозлыйбыз-борычлыйбыз. Яшел тәмләткечләрне, кычыткан һәм кузгалакны пешермичә (юкса таркалып бетәчәк), кайнап чыккач ук уттан алабыз. Ашны тәлинкәләргә бүлгәч, һәркайсына урталай бүленгән пешкән бытбылдык йомыркасын салып чыгарга мөмкин. Бик тәмле, матур һәм файдалы аш!

АЛМАЛЫ БИТЛЕК

✓ Яшел алманың кабыгын әрчеп, орлыкларын алып, вак тишекле угычтан уабыз. Согын сыккач, 1 йомырка агын салып болгатабыз һәм катнашманы биткә сылыйбыз. 15–20 минут чамасы тоткач, юып алабыз. Алма кислотасы биттәге тапларны бетерә, ә аксым тире күзәнәкләрен тарайтып, битне шомарта.

ЯШЕЛ ЧӘЙЛЕ БИТЛЕК

✓ 1 аш кашыгы коры яшел чәйне блендерда ваклап, шуңа 1 аш кашыгы майлы кефир өстибез. Масканы биткә сылап, 15 минут тотканнан соң юып алабыз. Яшел чәй тән тиресен чистарта, токсиннарны чыгара. Ә кефир биттәге тапларны, кара ноктаарны бетерә.

Белсәң, зыян итмәс

ИКМӘК ИСКЕРМӘСЕН

Эмальле кәстрүл төбенә 1 грамм ванилин (пычак очына алып) сибәбез. Икмәкне кәстрүлгә салып, өстен целлофан белән каплыйбыз. Болай эшләгәндә, ризык озак вакыт искермәячәк, хуш исен дә җуймаячак.

Белеп тор!

Токмач «шулпасы» серләре

Хуҗабикәләрнең күбесе токмач пешкән суны түгә. Ә бит аннан файдаланырга мөмкин!

✷ Коймак камырына өстибез. Сөткә бераз гына шул суны кушсаң, коймак күпереп, бик йомшак һәм тәмле булып пешәчәк.

✷ Фасоль яки борчакны җебетәбез. Болай эшләгәндә, кузаклылар үзенчәлекле бер тәмле тәм сеңдереп, тизрәк пешәчәк.

✷ Гөлләргә сибәбез. Ләкин су кайнар һәм тозлы булмаска тиеш! Сыеклыктагы крахмал гөлләрне тукландыра.

✷ Савыт-саба юу өчен кулланабыз. Майлы таба яки башка савытны токмач «шулпасы»на салып, бераз тотабыз. Крахмал майны бик яхшы эретә.

ГӨНАҺЫ ДА, ҖӘЗАСЫ ДА ЗУР

Соңгы арада җәмгыятьтә үз-үзенә кул салу, суицид кебек аяныч күренешләр арткannan-арта бара. Бу гөнаһтан ничек сакланырга?

Мөхәммәд хәзрәт МИФТАХОВ шушы четерекле мәсьәләгә ачыклык кертте.

– Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә: «Үз-үзегезне үтермәгез», – ди. Шул рәвешле Аллаһы Тәгалә бу гамәлне хәрам итте. Үз-үзеңне үтерү зур гөнаһ санала. Бу адымга барган кеше бу дөньядан гөнаһлы булып китә. Моның өчен бакыйлыкта бик зур җәза көтә. Бу дөньяда иң зур һәм катлаулы булып саналган проблема, борчу гомерен үз куллары белән үк өзеп, теге дөньяга күчкән кешегә уенчык кебек кенә тоелыр. Аның иң зур проблемалары ахирәттә башланачак. Шуңа күрә кеше нинди генә авыр хәлдә калса да, бу гөнаһтан сакланырга тиеш. Ислам дине кешенең газапларын киметү максатыннан аның үлемен якынайтуга да (эвтаназия. – **Д.Г.**) каршы.

:: Балалар, хәтта 80–90 яшькә җиткән өлкәннәр арасында да үз-үзләренә кул салу очраклары арта. Өлкәннәрнең кул салуы акылга зәгыйфьлек килүдән булса, ул җәһәннәмгә эләгәме?

– Җәһәннәмгә эләгү-эләкмәү бездән тормый. Кешене хөкем итәргә дә хакыбыз юк. Һәр очрак индивидуаль. Бар да Аллаһы Тәгалә кулында. Әмма акылга зәгыйфь кеше суицидка барса, бу аның өчен гөнаһ булып язылмый. Ник дигәндә, ул үзенең нәрсә эшләгәнен аңламый, белештерми. Гомумән, акылдан язган кешенең бу дөньядагы эшләре, гөнаһлары язылмый. Әмма Кыямәт көнендә аңа үз имтиханы булачак.

:: Кешенең бу гамәле гөнаһ булып саналмаган башка искәрмә очраклар бармы?

– Бу очракта дүрт искәрмә бар. Әгәр кеше, әйткәнемчә, үз акылында булмаса, балигъткә ирешмәгән (җенси яктан җитлекмәгән. – **Д.Г.**) икән, аны янау, куркыту хисабына мәҗбүриләп, үз-үзенә кул салдырган булсалар, кеше бу адымга суицидның гөнаһ икәнлеген белмичә барса, ул гөнаһ дип саналмый.

:: Балаларга үзеңне үтерүнең зыяны турында ничек аңлатырга?

– Балаларга бу хакта күп сөйләргә ярамый. Үзләре сорамаса, бу теманы бөтенләй кузгалтмавың хәерле. Психологлар яшьләргә наркотиклар, аларның зыяны турында гел сөйләп, искәртеп торырга кушмый бит. Ник дигәндә, болай эшләгәндә, киресенчә, тыелган әйберне татып, эшләп карыйсы килү теләге көчәя генә. Суицид очрагында да шул ук хәл. Ул хакта гел искә төшереп торырга кирәкми. Ярамый, дип тукып торсаң, балада аны эшләп карыйсы килү теләге уяныргa мөмкин. Ә инде ул бу темага үзе сөйләшергә теләк белдерсә, ата-ана баласының үз эченә бикләнгәнен күрсә, аңа бу дөньяда нинди генә проблемаң булса да, әлеге адымга барырга ярамаганлыгын, үз-үзеңә кул салып кына авырлыклардан котылып булмавын, киресенчә, бу адымнан соң проблемаларның башлануын аңлатырга кирәк. Дини тәрбия алып үскән бала да мондый адымнан ерак торачак.

:: Үз-үзеңә кул салу – шайтан шаяруымы?

– Шайтан һәрчак, кешеләр гөнаһ кылсын, бу дөньядан имансыз булып китсен, дип вәсвәсә кыла. Аның төп максаты – адәм баласын юлдан яздыру. Шуңа күрә үз-үзеңә кул салу да – шайтанның бер шаяруы.

:: Акчасын, бизнесын, эшен югалткан әзмәвердәй ир-атларның әлеге адымга бару очраклары да еш очрый...

– Монда гаеп кешенең үзендә. Алар еш кына бу дөньяга бирелеп, фани дөньяны Аллаһы Тәгалә дәрәҗәсенә җиткереп, акча артыннан куулары аркасында шушы

көнгә кала. Кеше хакыйкый рәвештә ахирәт турында уйласа, ул беркайчан да үз-үзенә кул салмаячак. Киресенчә, таптан малы, акчасы артык калса, аны игелеккә тотарга тырышачак. Әгәр кеше акчасын, малын, көчен, куәтен игелеккә җибәрә икән, Аллаһы Тәгалә аның күңеленә шатлык сала, тынычлык, аңлау иңдерә. Шуңа күрә бу дөньядагы тормыш кына түгел, ахирәт турында да онытмаска кирәк. Әйтик, үз эшен ачар алдыннан кеше мәктәп, университетта укыганнардан тыш, бик күп өстәмә белем туплый. Болар белән параллель рәвештә дини белем дә тупларга кирәк. Бу үзенә күрә бер ахирәт тормышына әзерлек булачак.

:: Кеше бозык, күз тию аркасында да үз-үзенә кул салырга мөмкинме? Аны бу адымыннан туктатып, гомерен саклап калып буламы?

Ильяс абый бүген ясый торган савыт-сабаларның үзенчәлеге шунда: ул аларны агач кисәкләреннән эшли. Аның өчен имән, каен, нарат, карама, юкә һәм зирек агачларын файдалана. Беренче карашка бизәкләр төшерелгән кебек тоелса да, чынлыкта барысы да – табигать бүләге, аның матурлыгы. Төрле агач кисәкләреннән күз явын алырдай матурлык пәйдә була. Мәсәлән, бер вазаны эшләгәндә җиде төрле агач кулланырга мөмкин.

– Караңгырак төс алыр өчен имәнне аммиак парында каралтып алам. Ике тәүлек эчендә агачның эче генә түгел, тышы да карала, – ди оста.

Якын дустым – «Ютуб»

Эшләремнең дәвамлы булуын телим. Монысы да оста куллы Ильяс Идиатуллин сүзләре. Үзе ике кыз үстергән әти булгач, бар белемен Әлкинең балалар иҗат үзәгендә малайларга тапшыра. Бирегә елына 40лап баланы укытып чыгара. Алга таба укучыларның шул юнәлеш буенча китүләре тагын да сөендерә, ди ул.

– Тактаны миннән дә остарак кисүчеләр бар, – дип горурлана остазлары. – Минем күзләр бик үк яхшы күреп бетерми хәзер, ә малайлар булдыра! Дөрес, баштагы өч айда үземә дә, аларга да шактый тырышырга кирәк, әлбәттә. Белгәнемне башкалар белән бик теләп уртаклашам, чөнки савыт-сабаны теләгән һәр кешегә барыбер үзем генә ясап бетерә алмыйм. Ә аларның мин күпчелек йортта булуын телим. Казан кибетләрендә агачтан ясалган савыт-сабалар ким дигәндә 1200 сум тора. Ә мин 400–500 сумга сатам. Халык сөенә-сөенә ала. Аларга карап мин куанам. Өлкән яшьтәге апаларга шактый арзан бәядән озатам. Бушка биреп җибәргән вакытлар да күп. Ярминкәдәге башка сатучылар аңламый, әлбәттә, мине. «Ник алай эшлисең?» – дип шаккаталар. Ләкин мин яхшылыкның яхшылык булып әйләнеп кайтасына ышанам. Бүген булмаса, иртәгә барыбер кайта ул. Кайтмаса да, күңелдә рәхәтлеге кала. Ярминкәдән кайткач, кемнедер сөендерә алуыма ике көн куанып йөрим. Күп вакыт шул апалардан соң бер абзый килә дә 15 мең сумлык товарымны сатып алып китә. Яхшылык озак көттермәде, дип сөенәм андый чакларда.

Алай гына да түгел, алтын куллы останың эшләнмәләрен чит илләрдә яшәүчеләр дә яратып алалар. Америка, Германия, Казахстан, Перу һәм башка илләрдән бүләккә дип заказ бирүчеләр дә шактый, ди. Мәсәлән, күптән түгел генә Франциядән заказ белән сандык ясаттырып алганнар. Агач остасы әйтүенчә, шахмат тaktaларына һәм сыннарга исә күбрәк җитәкчеләр заказ бирә.

– Минем якын дустым бар. «Ютуб» дип атала ул, – дип елмая оста. – Яңа ысулларны да шуннан өйрәнәм. Агач кисәкләреннән ясау ысулы исә катлаулылыгы белән җәлеп итте. Гомумән, эш никадәр авыр, эшләнмәләрне шуның кадәр теләбрәк ясыйм. Кызыксыну, азарт барлыкка килә. Кызганыч, яшьрәк чакта укыйсым калган минем. Белемем булса, күбрәк уңышка ирешкән булыр идем. Үзлектән өйрәнгәнлектән, агачның җелегенә 40 яшьтә генә үттем. Аның бар нечкәлекләрен, телен өйрәндем. Мәсәлән, агачның төбен тукмакка кулланырга ярый, ләкин ул уклауга бармый. Аңа нарат та ярамый: сумаласы чыга. Нараттан ясалган эшләнмәләрне лак белән дә буяп булмый, шул ук сумаласы этеп чыгара. Чыдамлы булмый. Ә кешеләргә озакка җитә торган сыйфатлы эшләнмәләр ясыйсы килә. Шунысы бар: минем савытлар ут һәм су яратмый. Аларны коры ризыклар өчен генә файдаланырга мөмкин.

Ильяс абый савыт-сабаларны киндер мае, балавыз белән дә буйый. Бу эшләрдә төп ярдәмчесе – хатыны Әлфия.

– Мин ясыйм, ул буйый. Шахматларны шомарту, савытларны буяу – барысы да аның өстендә. Соңгы вакытларда сатарга да аны ала башладым. Башта оялып торса да, соңыннан остарып китте, – ди гаилә башлыгы.

Оста куллы танышыбыз сүзләре буенча, язын, җәен ярминкәләрдә сата торган савыт-саба, кухня өчен кирәк-ярakларны ул кыш буе ясый. Мәсәлән, бер савытны ясап өлгертү бер атнага кадәр сузылырга мөмкин, ди. Вазаны ясау технологиясе – өч көн. Билгеле, бу вакыт эчендә башка эшләрне дә башкара.

– Әле ярый шушы һөнәрем бар дип куанам, – ди ул. – Кулым эшле, димәк, гаиләм ашлы. Күп эшне үзем башкаргач, акча да янга кала. Өченче ел пандемия вакытында эскәмияләр ясадым. Үзебезнең капканы да яңартасы идек. Белешкәч, 75 мең сумга исәпләп чыгардылар. Аларын да үзем ясарга тәвәккәлләдем. Нәтиҗәдә материал өчен 24 мең сум гына китте. Менә шулай аздан да күңел булып, рәхәт итеп яшәү яклы мин.

Зөһрә САДЫЙКОВА

ИКЕ ТӘГӘРМӘЧЛЕ ТОРМЫШ

Ел саен 20 майда Россиядә «Эшкә – велосипедта» акциясе уза. Асылы – двигательле транспорттан баш тартып, табигатькә һәм сәламәтлеккә азмы-күпме файда китерү. Бу акциядән Татарстан да читтә калмый. Гомумән, соңгы арада республикада әлеге транспортка өстенлек бирүчеләр артты.

vk.com

Моны саннар да дәлилли. Әйтик, «Ozon»ның матбугат хезмәте хәбәрләренә караганда, велосипед сатып алучылар саны, узган ел белән чагыштырганда, 30 процентка арткан. Бу хәл башка маркетплейсларда да күзәтелә. Ә ил күләмендә караганда, агымдагы елның март аенда велосипед сатуның гомуми саны 65 процентка арткан. Нәрсәдә икән моның сере? Велосипедта йөрүнең уңай, фәлсәфи яклары, педаль әйләндерүнең «романтикасы» – без шуларны ачыкларга тырыштык.

«Сәпид» кенә, димә

57 яшендә велосипедка утырып чыгып китә дә дөнья тирәли сәяхәт кыла. «Сәпидле романтика»ның серен белсә, ул белер. Татарстан Велосипедчылар берлеге рәисе Илдус Янышев безгә ике тәгәрмәчле дустына бәйле балачак хатирәләрен дә, 40та кабат педаль әйләндерә башлавын да сөйләде:

– Кечкенә чакта мин дә, башка малайлар кебек үк, «сәпид» турында хыялландым. Безнең аңа карата мөнәсәбәт үзгә иде. Утырдың да чыгып чаптың түгел. Рулен үзгәртәсеңме шунда, берәр нәрсә өстәп куясыңмы – кыскасы, аның янында бөтерелү, үз кулларың белән нидер майтару кызык тоелган ул чакта. Аннан соң, велосипедның рамы янсә «багажнигы»на матур-матур кызларны утыртып йөрү янсә руленнән кулларны ычкындырып җилдерү үзенә күрә бер горурлык хисе уята иде. Бераздан миңа 16 тулды. Велосипед түгел, машина белән кызыксына башладым, хыяллар үзгәрде. «Иске» дустыма 40та гына кайттым. Бер дустымның өйдән ерак китми генә велосипедта йөреп кайтырга тәкъдим итүеннән башланды ул. Көннән-көн чакрымнар да, кызыксыну да артты.

Ә дөньяга карашымны үзгәрткән очрашу Америкада булды. Мин ул чакта илләр буйлап машинада сәяхәт итеп, үземне «текә»гә саный идем. Алманиядән Аляскага кадәр велосипедта сәяхәт кылучы берәүне күргәч, бу фикердән кире кайттым. Менә кем «текә» икән ул!

Казанга кайткач, һич югы Ульянга кадәр барып җитәргә карар кылдым. Ул вакытта, ялгышмасам, 46 яшьтә идем. Европаны әйләнеп кайтканнан соң, дөнья тирәли сәяхәт турында уйлана башладым. Шулай итеп, 57 яшем тулуга, 2017 елның апрелендә Татарстаннан кузгалып, 25 мең чакрым юл узып, дөньяның 13 илен күреп, 2018 елның октябрендә кире кайтып җиттем, – диде ул.

Велосипедта йөрүнең үз фәлсәфәсе бар. Ул без уйлаганнан күпкә тирәнрәк. Илдус Янышевның фикерләре әнә шуңа инандыра. «Без – уйлый торган җан ияләре. Шушы уйлар белән нәрсә дә булса эшләр өчен безгә тән бирелгән. Борынгы заманнарда кешеләр исән калу өчен сәяхәт иткән. Илләр, җирләр гизгән, шул рәвешле шәхес буларак формалашкан. Ләкин бер мизгелдә кешелек хәрәкәтләнүдән туктаган. Бер урыннан икенчесенә хәрәкәт итү чаралары арткан. Бүген без самолетта очуны да сәяхәт дип атыйбыз. «Юл» сүзенең мәгънәсе үзгәрде. Аның дәвамы турында түгел, ахыргы ноктасы турында күбрәк уйлыйбыз. Бу безне рухи яктан гаять чикли. Шул ук юлны велосипедта янсә җәяү узганда, дөньян да, күңелен дә, гадәт һәм карашларың да үзгәрә. Ниһаять, тормышның моңарчы күрмәгән якларына игътибар итәсең, бөтенләй башкача фикерле башлыйсың. Ирек! Бәхет! Хис-кичерешләрне сүзләр белән генә аңлатып булмый. Билгеле, практик яклары да хәйран. Сәламәтлегең ныгый, яшәү көчең, энергияң арта. «Двигатель»дән баш тартып, табигатькә азмы-күпме файда китерәсең», – ди ул.

Шәһәрдә генә түгел, салада да җилдерәләр ул «сәпид»тә! Элек малай-шалайлар гына булса, хәзер әбиапалар да тапкан җаен. Тиз бит, рәхәт тә әле. Балтач районының Арбор авылында яшәүче Рафилә Һадиева шулай ди. «Бөтенебез йөрибез велосипедта. Фермада эшләүче кызлар урам тутырып эшкә җилдерә. Олы апалар да велосипедта йөрергә ярата. Апалар, дигән булам, үзем дә 55тән уздым бит *(көлә)*. Теләгән җиреңә тиз генә барып җитәсең, сәламәтлеккә дә файдасы күп – уңай яклары җитәрлек. Варикоз борчый мине, педаль әйләндерүнең файдасы бар – аякка җиңелрәк басам хәзер. Иялӊнеп беттек, сәерсенеп караучылар юк», – дип сөйләде ул безгә.

Хәрәкәте дә, бәрәкәте дә

Рафилә апа да әйтте инде: велосипедта йөрү сәламәтлеккә уңай йогынты ясый. Аның файдасы һәм зыяны турында тулырак табиб-терапевт Гөлназ Шәйдуллинадан белештек.

– Велоспорт, беренче чиратта, йөрәк-кан тамырлары системасы, терәк-хәрәкәт аппараты өчен файдалы. Велосипедта йөрү мускул, буыннарны ныгыта. Кан әйләнеше, иммун һәм сулыш алу системасы яхшыра. Ул шулай ук җенси функциягә дә уңай йогынты ясый, чөнки велосипедта йөргәндә оча сөягендә кан яхшырак йөри башлый. Билгеле, теләсә кайсы спорт төре кебек үк, велоспорт йокыга, психик сәламәтлеккә дә файдалы. Ә инде зыянына килгәндә, барлык куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәгән очракта, велосипедта йөрү сәламәтлеккә тискәре йогынты ясамый. Җәрәхәтләрдән саклый торган һәм уңайлы кием сайлау, үзенә артык авырлык китермәү мөһим.

Яхшы велосипедны ничек сайларга? «Sweet_kids» кибете менеджеры Фәнил РӘХИМУЛЛИН киңәшләре:

- иң беренче чиратта аның авырлыгына игътибар итәргә кирәк. Велосипед авыррак булган саен, анда йөрү кыенрак;
- амортизациясе булганнарына өстенлек бирегез. Ул юллардагы сикәлтәләрне җиңелрәк «кичерергә» ярдәм итә. Күп велосипедларда аны кирәкмәгән чакта блокка куеп та була;
- велосипед алганда, тормозларга да игътибар итәргә кирәк. Алар берничә төрле була. Куркынычсызлык өчен «кыса торган» түгел, дисклы системаны сайларга киңәш ителә. Бигрәк тә, велосипедны балагыз өчен сайласагыз;
- тизлек күчерү мөмкинлеге булган велосипедларның эшләү механизмын тикшереп алу зарур;
- шулай ук педальләрнең ныклыгы, киңлеге һәм аякка уңайлы булуын, утыргычның сыйфатын да игътибарсыз калдырмагыз.

Сак бул!

Татарстанның ЮХИДИ идарәсе мәгълүматларына караганда, агымдагы елда велосипедчылар катнашында барлыгы 16 юл һәлакәте булган, аларда 16 кеше зыян күргән. Шуларның 8е – балалар.

Бу – кызык!

Велохәрәкәтнең тагын бер кызыклы ягы бар бит әле. Алман илендәге Кельн университеты хезмәткәрләре югары белемле кешеләрнең велосипедны машинага караганда өстен күрүләрен ачыклаган. Тикшеренү нәтиҗәләренә караганда, белем дәрәҗәсе югарырак булган кешеләр, машина урынына велосипедны сайлап, үзләрен ярлы итеп күрсәтүдән курыкмый. Ә белем дәрәҗәсе түбәнрәкләр, киресенчә, тышкы атрибутларга һәм аларның мәгънәсенә игътибар итә. Хәрәкәт итү чарасы белән кешенең белеме, дөньяга карашы арасындагы бәйләнеш турында психолог Васил Шәмсевәлиева менә нәрсә ди:

– Озак еллар дәвамында кешелек тышкы кыйммәтләр һәм атрибутларны кайгыртты. Хәтта күпмедер дәрәҗәдә аларга табыну да күзәтелде. Бүген исә кешелекнең эчке дөньяга таба борылуын күрәбез. Моның сәбәбе берничә. Бердән, тышкы атрибутлар тотрыклы түгел. Ә эчке дөнья, тормыш ничек кенә үзгәрсә дә, тотрыклы кала. Кеше шуңа күрә таянычны тыштан түгел, үзеннән, эченнән эзли. Һәм таба да. Ул дөньяның мәгънәсенә төшенергә тырыша, үзен өйрәнә, тормыштагы төп миссиясе, үзеннән соң калдырасы эз турында уйлана. Эчке дөнья кыйммәтләре белән яшәү шактый авыр. Бу зур рухи көч таләп итә. Ләкин, ничек кенә булмасын, игътибарны тышкы дөньядан эчкесенә күчерү кешелек дөньясының үсешенә уңай йогынты ясар дип уйлыйм.

* * *

Велосипедның популярлыгы арта, дип сөйләсәк тә, кайбер илләрдәге кебек төп транспорт чараларының берсенә әйләнгәнче шактый сулар агар әле. Бәлки, ул дәрәҗәгә бөтенләй җитә алмабыз. Ничек кенә булмасын, утырып йөрүдән бигрәк, педаль әйләндерүне өстен күрүчеләр арта икән, бу илнең «сәламәтлеге»н ныгытачак кына.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

САН

Парк-скверлар, яр буйларын исәпкә алмаганда, бүген Казанда **15** чакрымга якын велоюл исәпләнә. Киләчәктә аның гомуми озынлыгын **75** чакрымга кадәр арттырырга ниятлиләр. Чагыштыру өчен: Әлмәттә мондый юлларның гомуми озынлыгы – **100** чакрымнан артык.

ЯМАН ЧИР ТУРЫНДА ОНЫТКАН КАМИЛӘ:

«ЯШӘҮНЕҢ КАДЕРЕН БЕЛЕГЕЗ»

Язылганга кайтып

Кайчандыр ул бала гына иде әле. «Ватаным Татарстан» газетасы оештырган хәйрия концертының икенчесе аңа ярдәм итү ниятеннән үткәрелде.

Казанның үзәгендә татар эстрадасы җырчыларын җыеп, 4 сәгатьлек концерт оештырдык. Ул чакта 14 яшьлек Камилә Гыйбадуллинага операция ясау өчен 250 мең сум акча җыелды.

Камилә белән әле дә элемтәдә торабыз. Тормышында үзгәрешләр күп булган. Бу көннәрдә Казанга кунакка кайткан.

– Авыру мине бөтенләй үзгәртте. Табиблар, синдә яман чир, дигәч, мин аны җиңәм, дип яшәдем. Ул чакта әнием дә уҗәтлегемә шакката иде, – дип сөйли ул. – Дөрес, авыру минем балачагымны урлады. Миңа бик тиз үсәргә туры килде. Хастаханәдә ятканда, гомере өзелгән кешеләрне көн саен күрдем. Дусларым да китеп барды. Авыр булды, әмма мин яшисемә ышандым.

Камилә Мәскәүнең бер университетына укырга керде. Химия терапиясе, нурланыш алганнан соң да бик озак табибларга йөрде әле ул. Авыру аны тормышка башкача карарга өйрәтте.

– Мин һәр көннән ямь табып яшим. Мәскәүдә укый башлагач, Ливаннан килгән гарәп егете белән дуслаштык. Бер елдан соң миңа кабат хастаханәгә ятарга туры килде. Яман шеш булган урынның тиресе нурланыш алып юкарып тишелде. Шуңа операция кирәк булды. Авыр чагымда дус егетем белән тагын да якынайдык. Аннары инде мин аның үз кешем икәнен аңладым, – ди Камилә.

Яшьләр эшне озакка сузмаган. Камилә кияүгә чыккан. Хәзер алар ире белән Ливанда яшиләр.

– Әлегә иремнең әти-әнисе белән бергә көн күрәбез. Әмма Россиягә кайту теләгебез бик зур. Аларда бит хәлләр мактанырлык түгел. Тормыш авыр, – ди Камилә. – Ирем белән никах укыттык. Җәйгә әниемне чакырып, иремнең туганнары белән таныштырып, кечкенә генә бәйрәм ясыйсы килә. Аннан соң, Татарстанга кайтып, минем якыннарымны җыеп утыру теләге бар.

Камиләдән, гарәп килене булу ошыймы, дип тә сораштык. Ул зарланмый. Ире белән икесенең дә уй-фикерләре уртак икән. Хәтта бергәләп дөрес итеп туклана-лар да.

– Өйдә инглиз телендә сөйләшәбез. Ирем русча да аңлый. Мин татарча белгәч, гарәпчәгә дә өйрәндем. Уртак сүзләребез күп икән, – ди Камилә. – Язмышыма үпкәләмим. Авырлыклар мине яшәргә өйрәтте. Яман чир хакында уйлаганым юк. Табиблар да кистереп, башка кабатланмас, диме. Әмма гел яхшыга ышанам. Хәзерге көнемә рәхмәтлемен. Вак-тøяк авырулар була инде ул. Иң мөһиме – минем балачагымны урлап, күз яшьләре түктерә торганы башка булмасын!

Камилә әнисе хакында яратып сөйли. Яратмаслык та түгел шул Илмираны! Камилә авырганнан соң, әтиләре ташлап киткән иде аларны. Ике ел элек Альберт абый якты дөнья белән хушлашкан. Илмира ханым исә, кызы савыккач, яман чир белән авыручы сабыйлар бүлегендә эшли башлаган.

– Әнием тәүлек буе эштә. Бик арый. Яман чиргә каршы көрәшүче сабыйларны күрү йөрәккә җиңел түгел. Әмма әнием кешеләргә ярдәм итүенә сөенеп, эшен бик якын итә, – ди Камилә.

КАЙГЫ ҮЗЕ ГЕНӘ КИЛМИ

Чүпрәле районының Иске Чүпрәле авылында яшәүче 67 яшьлек Рәшит абый Баһаветдинов июньне яратмый. Шушы айда иң якын кешеләре – улы, хатыны, әнисе вафат булган. Авыр хәсрәтләрне күтәрә алган, үзендә яшәргә көч тапкан ул.

– Улыбыз авылда Сабан туе көнне һәлак булды. Әле көндез генә мәйданда көрәшеп йөргән 16 яшьлек егетнең кичен җансыз гәүдәсен алып кайттык. Кечкенәдән техника рәтен белеп үсте Тимур. Мотоциклны иртән сүтеп, төшкә җыеп та куя иде. Улыбызны дусты килеп алды. Авыл башында мотоциклы ватылган икән. Тимур каршы килмәде, ярдәмчел иде. Юл читендә мотоциклны төзәтеп яткан егетләр өстенә рульдә исерек йөртүче утырган машина килеп менә. Дус егете кырыйга очып, исән калган, безнекен коткара алмадылар, – дип искә ала Рәшит абый. – Бик акыллы иде балам. Үләренә берничә көн кала ул әнисенә «Аятел-көрси» сүрәсен язып биргән иде. Кирәге чыгар, ди. Бу кайгыдан догалар укып тынычланырга тырыштык.

Тимурның үлеме бөтен авылны тетрәндерә. Әнисе Дилүзә апа да, Рәшит абый да бала хәсрәтен күтәрерлек көч таба үзләрендә. Ничек тә яшәргә кирәк, ди алар. Олы уллары Радик та бар бит әле! Әнә шул бала аларны коткара да инде. Әмма капкаларын тагын кайгы җиле кага. Беренчесе икенчесен алып килә.

– Башта бар да яхшы иде. Кинәт кенә хатыным табибларга йөри башлады. Казанга чыга да китә. Мин аптырап сорасам, хатын-кызлар табибына гына күренеп кайтам, ди торган иде. Үзенең авыруының сиздермәде. Мин гел эштә булдым. Әмма күңелгә барыбер шик керде: хатыным нәрсәдер яшерә кебек. Бервакыт ул хастаханәдән кайтып сумкасын куйгач, тиз генә табиб биргән язуларның күчермәсен үземә алдым. Эшемә барып укып карасам, Дилүзәдә яман чир икән. Лимфа төеннәрендә яман шеш. Әлеге сүзләрне уку авыр булды. Нишләргә дә белмәдем, – ди Рәшит абый.

Бу вакытта Дилүзә апа иренә сиздермичә генә ике операция ясаткан була инде. Мәкерле авыру үзенекен эшли. Дилүзә апаның хәле көннән-көн начарая. Аны Казан хастаханәсенә салалар. Рәшит абый хатыны янынннан 3 ай буена китмичә, аны үзе тәрбияли. Өйләренә кайтарып җибәргәндә, 24 көн гомере калган, диләр. Әмма Рәшит абый бу хакта ишетергә дә теләми. Хатынын тагын 3 ай яшәтә әле ул. Җылы сүзен, ятратуын кызганмый. Аның шулкадәр сабыр булуына бөтен авыл шакката.

– Тормышта иң кирәге – сабырлык. Кызулык белән берни эшли алмыйсың. Ә хәзерге яшьләр түзем түгел, – ди Рәшит абый. – 38 ел яшәгән газиз хатынымны җир куенына салу җиңел булмады. Ул чактагы хәлемне үзем генә беләм. Ярый, улымның гаиләсе бар. Киленемә чиксез рәхмәтлемен. Дилүзәмне югалтканга 5 ел була быел. Киленем килеп бөтен өемне җыештырып, юып китә. Гел ярдәм итеп тора.

Өйләнергә уйламый да Рәшит абый. Йортка ят кеше кертәсем килми, ди. Хәсрәтен басар өчен, эшкә чума. Үзенә шөгыль таба. Бакчасында төрле җиләк-җимеш үстерә, кайнатмаларны да үзе әзерли. Өен дә яшеллеккә күмә, 50дән артык гөле бар икән.

– Гөлләремне күреп, күпләр соклана. Бу арада кунаклар килгән иде. Өчесенә күз тиде, – ди Рәшит абый. – Гөлгә дә чәчәк атар өчен көч кирәк. Кешегә тагын да катлаулырак. Спорт белән дус мин. Элек биеп тә йөрдем әле. Лаеклы ялда булсам да, эшкә киредән чакырып алдылар. Кеше арасында көннең узганын да сизмисең. Күңел төшереп, моңсуланып та утырып булмый. «Бабай», – дип өзелеп торган оныкларым бар. Мин бәхетсез түгел!

Рәхмәт ишетү рәхәт

Күтелмәгән ярдәм

10 май көнне бик нык авырып киттем. Хәлем бик авыр иде, хастаханәгә алып киттеләр. Реанимация бүлегендә ятканда, телефоныма хәбәрләр килә башлады. Хәлем яхшырып киткәч, ачып карасам, картама акча килә икән. Шунда ук «Ватаным Татарстан»нан Гөлгенә Шиһаповаың шалтыратканы исемә төште. Ул бит мине газетага язып, ярдәм оештырам, дигән иде.

Яраткан газетамның 6 нчы май санында мин күргәннәр хакында «Яшәп каласы килә» исемле язма басылып чыккан икән. Акча гына салмадылар, шалтыратып хәлемне белүчеләр дә булды. Авыр чагымда газета укучылар миңа ярдәм итте. Картама килгән акчага дарулар алдым, калганын кирәк-яракларга тоттым.

Хикмәт акчада да түгел, кешеләрнең игътибарына күңелем сөенде. Миңа ярдәм иткән һәркемгә, редакция коллективына чын йөрәктән рәхмәтемне белдерәм. Тагын бер кат Аллаһы Тәгаләнең барлыгына инандым. Бер теләгем генә бар – яшисем килә! Улымны аякка бастырып, аның өйләнгәнен күрергә насыйп булса иде. Миңа ярдәм иткән һәркемгә сәламәтлек телим. Иң зур байлыгыгызның кадерен белеп яшәгез.

Мария ШАРОНОВА.
Теләче районы Үзәк авылы

Альбертка гармун кирәк!

Казанда яшәүче егет тумыштан эпилепсия чиреннән интегә. «Чирем аркасында эшкә урнаша алмыйм. Дәүләттән 13 мең сум пенсия алам. Әмма ул акча даруларга да җитми. Әле бит ашыйсы, киенәсе дә килә. Фатир өчен дә түләргә кирәк», – ди әнисе белән яшәүче егет.

Альберт кечкенәдән гармунда уйнарга өйрәнгән. Әнисе туган көненә бүләк иткән гармун белән метрода уйнап, акча эшли икән.

– Кешеләр биргән акча булмаса, белмим, нишләр идем. Күп түгел инде ул. Әмма тормышны алып барырга җитеп тора. Дарулар да кыйммәтләнде хәзер. Миңа кирәклеләрен бөтенләй сатмый башладылар. Бер дарудан икенчесенә күчкәндә, өянәкләрем еш кабатлана, – ди ул.

Альбертка гармун кирәк. Үзенеке бик таушалып, искереп беткән.

– Метрода утырганда яныма килеп, ни өчен гармун уйнап, акча җыюым турында сорыйлар. Аңлатып бирәм. Шөкер, кешеләр кимсетми, – ди ул. – Гармун алырга иде. Әмма ул кыйммәт.

Егетне сөендерергә теләүчеләр редакция белән элемтәгә керә ала. Телефон номеры: 222-09-67.

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

ФӘРИТ БИКЧӘНТӘЕВ:

«ТАМАШАЧЫНЫ ЯРАТЫРГА КИРӘКМИ, АНЫ ХӨРМӘТ ИТӘРГӘ КИРӘК»

Туксанынчы елларда «чирләткән» әсәр, директор белән режиссер мөнәсәбәтләре, милли кадрлар, драматургия хәлләре, сәхнә тәҗрибәләре. Камал театрының баш режиссеры Фәрит БИКЧӘНТӘЕВ белән юбилее алдыннан әнә шулар хакында сөйләштек.

:: Мөһаҗирлек темасына сез беренче тапкыр гына алынмыйсыз. «Ак калфагым төшердем кулдан» спектаклендә дә шул ук фикер күтәрелә. Бу темага кат-кат әйләнеп кайтуның сәбәбе нәрсәдә?

– «Болганчык еллар», «Мөһаҗирләр» романнары белән мин бик күптәннән «чирлим» инде. Туксанынчы елларда аны миңа Марсель Сәлимҗанов тәкъдим итте. Әдәбият турында сөйләшеп утырганда, сүз иярә сүз чыгып, ул миңа Мәхмүт Галәү турында сөйләп китте. Романның төп нөсхәсе югалып, аның урысчадан тәрҗемә ителүе дә уйландырды. Марсель абый исә романны телевизион спектакль итеп күрүен дә әйтте. Менә шуннан бирле шушы әсәр кармагында инде мин.

Еллар узды, минем һаман да «Мөһаҗирләр»не зур масштабта күрәсем килде. Әсәр турында режиссер Илдар Ягъфәровка да сөйләдем. Башка режиссерларның да кылларын тартып карадым. Илдар Матуров хәтта аның сценарием да язды, ләкин фильм һаман төшерелмәде. Шуннан без инсценировкага конкурс игълан иттек. Ике автор әлеге конкурста җиңеп чыкты. Аның берсе – мәрхүм Фәнәвил Галиев, икенчесе – Илтөзәр Мөхәммәтгалиев. Фәнәвил Галиев инсценировкасы буенча режиссер Ренат Әюпов Минзәлә театрында спектакль дә куйды. Ниһаять, миңа да вакыт җитте кебек. Илгиз Зәйни белән Илтөзәр Мөхәммәтгалиев инсценировкаларын берләштереп, спектакль әзерләдек. Әлегә тамашачы беренче өлешен – «Болганчык еллар»ны караячак. «Мөһаҗирләр» ноябрь аенда дөнья күрәчәк. Ике өлеш бергә, ике тәнәфес белән дүрт сәгать ярымлык спектакль булачак.

:: Спектакльне «Ирдәүкә» дип атау да кызыклы. Бер караганда, хәзер дөнья – ирдәүкәләр кулында.

– Ул заманда бу сүз икенчерәк мәгънәдә йөргән.

:: Прозага алыну авырдыр бит?

– Минем Гаяз Исхакыйның «Көз»ен, «Курчак туе»н, Аяз Гыйләҗевнең «Әтәч менгән читәнгә»сен куйганым бар. Татар классикасын, гомумән, прозаны куюның үз авырлыклары бар. Юлын тапсаң, аның да авырлыгы юк.

:: Заманча куелышы буламы, классикмы?

– Мин аны бик аермыйм. Ничек була соң ул заманча? Әйбәт куелса, ул барыбер заманча килеп чыга. Миңа калса, бу әсәр бүгенге заман белән тәңгәл килә. Анда – алдауга корылган җәмгыятьтә халык язмышы. Хәер, теләсә кайсы җәмгыять алдауга корыла.

:: Соңгы еллар репертуарын алсак, «Сүнгән йолдызлар», «Әтәч менгән читәнгә», «Исәнмесез», тиздән «Мөһаҗирләр» ... Болар барысы да – исәнме әле без, киләчәгебез бармы, йолдызыбыз сүнмәгәнме кебек сорауларны үз эченә алган классик әсәрләр. Бу – заман таләбеме, сезнең күңел халәтеме?

– Күңел халәте. Әйтик, «Сүнгән йолдызлар»га мин Кәрим Тинчурин әсәрен тулаем кую өчен алындым. Чөнки ул пьесаның соңгы пәрдәсен нишләптер һаман төшереп калдыралар. Анда, зират буенда көтүче бабай белән малай диалогы бар. «Патшалар үзләре сугышмыйлар, халыклары сугыша» дигән җөмләдән башланып китә. Менә шул өзекне кертәсем килде.

:: Сезне европача фикер йөртә торган чын татар режиссеры, диләр. Килешәсезме?

– Төрлечә сөйлиләр инде. Мин – татар театры режиссеры. Европа театрларын күп күрдем, ул минем күңелгә ятышлы түгел. Минем тамырларым монда.

:: Төрле тәҗрибәләргә ничек карыйсыз? Әйтик, Нурбәк Батулла спектакльләренә.

– Әйбәт карыйм. Яшьләрнең фикерләү рәвеше үзгә, алар дөньяны әнә шулай күрәләр. Ул бит начар түгел инде. Нурбәк Камал театрында да биюләр куя. Мәсәлән, «Болганчык еллар»да ул куйган биюләр бар. Бик кызыклы эш килеп чыкты.

:: Ләкин бит Нурбәкләрнең «Дәрдмәнд» һәм башка спектакльләрен күпләр кабул итә алмады. Бигрәк тә өлкән буын интеллигенция вәкилләре. Аның сәбәбе нәрсәдә икән?

– Ул элек-электән шулай. Заманында Тукайны да кабул итмәгәннәр. Тикмәгә генә аталар һәм балалар мөнәсәбәтләренә багышланган әсәрләр тумаган бит инде. Каршылык еш кына дөрес юлны табарга ярдәм итә. Тәнкыйтьләүгә дә әйбәт карыйм мин. Битараф кына булмасыннар. Менә анысы куркыныч.

:: Алай дисез дә, Камал театры тәнкыйтьне бик авыр кабул итә бит.

– Әйе, баштарак тәнкыйтьне авыр кабул итә, әмма исәпкә ала идем. Профессиональ тәнкыйть булса, билгеле. Аш булмәсендә үзара сөйләшкәннән соң туган «тәнкыйть»не, наданлыкны кабул итә алмыйм. Кызганыч, безнең театр тәнкыйтьчеләре юк дәрәҗәсендә. Журналистика бар, әдәбият белгечләре бар, театр тәнкыйтьчеләре юк.

:: Сүз уңаеннан, милли кадрлар белән тәэмин итү ни хәлдә? Берничә ел элек театр бүлегендә бюджет урыннары булдыру мәсьәләсен күтәргән идегез. Ул мәсьәлә хәл ителдеме?

– Хәл ителәчәк, диләр. Әмма бу – бик катлаулы мәсьәлә. Минемчә, ул һаман да бер урында таптана. Милли кадрлар булдыру, укыту мәсьәләсен заманында Шамил Закиров белән күтәргән идек. Нәтиҗәдә мәдәният институтында театр факультеты оешты. Аннан актерлар да, режиссерлар да чыккалады. Тик, минемчә, режиссерларны барыбер Мәскәүдә тәрбияләргә кирәк. Монда тәрбияләп була, ләкин ул гына җитми. Аларга зур театр казанында кайнарга, Мәскәү, Санкт-Петербург театрлары премьераларын да карап барырга кирәк. Шул ук «Алтын битлек»кә җибәрергә кирәк, бу исә финанс мәсьәләсенә килеп төртелә. Икенче яктан, режиссерлар күп була алмый. Мәсәлән, мин укыган курста 15 студент иде. Шулардан өч кеше генә – режиссер, башкалары бүтән профессияләргә китте.

Училищеда тугыз егет, тугыз кыз укый. Күбесе – авыл балалары, алар белән эшләү кызык. Тел мәсьәләсе төрлечә, әмма начар түгел. Театр училищесына киләләр әле, ә менә мәдәният институтында хәлләр катлаулырак. Яшьләр эстрада бүлегенә килә яки бик күп татарлар рус бүлеген сайлый. Беренчедән, тел белми, икенчедән, карашлары Мәскәүгә төбәлгән. Менә бу чир инде.

:: «Татарны беркем дә бетерә алмый, ләкин ул үз-үзен юкка чыгара ала». «Курчак туе» спектаклендә әйтелгән фикер бу. Соңгы елларда шактый вакыйгалар булды, ничек уйлыйсыз: без бетү юлындамы, әллә терелү юлындамы?

– Бер караганда, тернәкләнәбез кебек. Төрле чаралар үткәрелә, Марат Әхмәтов җитәкчелегендәге тел комиссиясе башкарган эшләр өметләндерә. Иртәгә нәрсә буласын беребез дә әйтә алмыйбыз, ләкин иртәгәбез өметле булсын өчен булдыра алганны эшли алабыз. Мин өметләнәм.

Менә мин улыма карыйм. Йосыфка – 29 яшь, татарча шәп сөйләшә, җомга намазларына йөри. Каян килә ул аңа? Без бит Люция белән мәчеткә йөрмибез. Дуслары, даирәсе шундый..

:: Пандемия чикләүләре акрынлап бетерелә бара. Театр әлеге сынауда сынатмады шикелле. Алга таба ни булыр?

– Мин оптимист бу мәсьәләдә дә. Театрга яшьләр килә, зал яшәрә... Заманалар авыр булган саен, халык театрга, сәнгатькә, матурлыкка тартылган. Бу – язылмаган канун. Әйтик, менә бүген «Зәңгәр шәл» куела. Зал тулы.

:: Режиссерның үз драматургы булырга тиеш, диләр. Марсель Сәлимҗанов Туфан Миңнуллин белән эшләгән. Сезнең даими драматургыгыз бармы?

– Марсель абый белән Туфан абый тандемы башка кабатлана алмас инде ул. Туфан абый ул драматургиядә кабатланмас күренеш иде. Беренчедән, үзен тулаем иҗатка багышлаган, башка эшләр белән шөгыльләнмәгән. Икенчедән, театр кануннарын белә һәм театр белән яши. Хәзер исә язучылар театрга йөри дип мактанып булмый. Кризис исә бездә генә түгел, рус драматургиясендә дә, Европада да. Шуңа күрә театрлар прозага мөрәҗәгать итә. Татар прозасында байлык җитәрлек. Мин Мәхмүт Галәү әсәренә алынсам, Айдар Җаббаров Әмирхан Еникинең «Рәшә» повестена алындым.

> Безнең бәла – профессиональ язучылар булмауда. Рус драматургиясендә дә журналистлар, филологлар, тарихчылар яза. Элек Горький институты бар иде, анда профессионалларны әзерләделәр...

:: Театр оештырган лабораториядә «Томан», «Парковка» кебек спектакльләр чыкты. Бәлки, шундый укулар оештырырга кирәктер.

– Оештырып карадык. Язып китмәделәр бит. Драматургия – бик катлаулы, үзенә тугрылыклы булуны ярата торган жанр. Туфан абый дисез, ул бит иҗатка башыаягы белән чумган иде. Ул рус драматургиясен дә белә һәм андагы хәлләрне өйрәнеп, шуларга капма-каршы яза иде. Андый кеше әлегә юк шул.

:: Илгиз Зәйни әсәрләре?
– Ул үзе яза, үзе куя. Заманасы икенче. Илгизнең дә драматургия белән генә шөгыльләнергә вакыты юк. Берьюлы берничә эш алып бару драматургиягә тәэсир итми калмый, билгеле.

:: Театр әһелләре берлеге җитәкчесе буларак, милли театрларның хәлен ничек бәялисез? Кече шәһәрләр театрлары ничек яши?
– Кече шәһәр театрлары күтәрелештә. Аларга бигрәк тә «Бердәм Россия» гранты да ярдәм итте. Ул грантларга алар читтән режиссерлар чакыралар, бу сыйфатны үзгәртте. Актерлар үсте, режиссерлар ныгыды. Әтнә театры фестивальләрдә үзенә игътибар җәлеп итте. Минзәлә театрында күтәрелеш сизелә, чөнки анда яңа директор килде. Күп нәрсә директордан тора бит. Чөнки хәзер финанс мәсьәләсе беренче урында тора.

:: Сүз уңаеннан, театрларда «сәнгать җитәкчесе» дигән яңа вазыйфа барлыкка килде. Элек тә ул бар иде, ләкин бер иде. Хәзер Чаллыда, Курчак театрында. Сәнгатьне дә, финанс мәсьәләсен дә бер кеше алып бара аламы?
– Бу мәсьәләнә һәр театр, һәр кеше үзе хәл итә. Мин, мәсәлән, ул тәкъдимнән шунда ук баш тарттым. Заманында Марсель абый да баш тарткан. «Кадаклар өчен, бәдрәф бүлмәсендәге кәгазьләр өчен җавап бирәсем килми. Шамил директор булсын, мин режиссер булам», – дигән. Күп кенә театрлар безнең модельне куллана. Килешүдә без икебез дә – директор да, режиссер да – гамәлгә куючылар.

:: Шул ук вакытта режиссер белән директор уртак тел тапмаган театрлар да бар.
– Алар бик күп. Андый җирдә таякның авыр башы артистларга, хезмәткәрләргә төшә. Бу – куркыныч күренеш. Бу театрларда сәнгать җитәкчесен билгеләү отышлы. Чөнки директорны ул эшкә ала. Күп театрларда исә директор режиссерны яллый.

:: Камал театрының яңа бинасында түгәрәк сәхнә дә бар. Аңа нинди бурыч йөкләнәчәк?
– Ул сәхнәнең булуын мин теләдем. Чөнки менә бу диварлар, чикләнгәнлек алҗыта. Ә ул сәхнәнең диварлары, түбәсе ачыла, күл һәм күк күренеп торачак. Суфичылык идеяләре урыны булыр дип ниятләнә.

:: Чикләргә күнеккән тамашачы бу яңалыкны кабул итәрме соң?
– Безнең тамашачыда яңалыкка тартылу бар. Мин аны сизәм, тоям. Шуңа күрә курыкмаска кирәк. Әйтик, без кече сәхнәдә Фоссены куйдык. Колак ишетмәгән драматург – бердән, икенчедән, спектакль кичке тугызда күрсәтелде. Тамашачы килерме дигән шик булды билгеле. Әмма юкка. Без бөтенләй икенче тамашачыны күрдек.

> Тамашачыны гадиләштерергә ярамый. Кайвакыт режиссерлар, безнең тамашачыга ярар, дигән җөмлә ычкындыра. Андый кешенең урыны театрда түгел. Тамашачыны яратырга кирәк, димим, аны хөрмәт итәргә кирәк.

:: Фәрит Рифкатович, сезнең – яшәгән һәм эшләгән кадәресенә йомгак ясый торган көннәрегез. Туган көн уйландырамы?
– Минем өчен бернәрсә дә үзгәрмәде. Дискомфорт кына тоям. Артык игътибарны яратмыйм.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

< Дәвамы. Башы 12 май санында

МАРАТ ӘМИРХАНОВ

ШӘҺРЕ БАНУ

«Төсләр балкышы» китабыннан.

Бүләкләр бирешү тәгәлләнүгә, кунакларны һәм даирәне аш мәҗлесенә чакырдылар.

Мең кеше сыйдыручы бу утау-киез өй үзе бер сәнгать әсәре иде.

Чаңгырагы киртештән,
Увыгы бар көмештән,
Бусагасын бурлаткан,
Кирәгәсен сырлаткан
Утауга инде иләт –
Алтмыш терәкле ак утау.

Нәкъ уртада – алтыннан коелган, яфраклар белән бизәлгән зур күчмә тәхет. Аяклары көмештән, өске өлешендә күктә атышып уйнашкан йолдызлардай асылташлар җем-җем килә.

Җыелышучылар мәликне баш киемнәрен салып сәламләделәр.

Тәхет киң вә зур иде. Мәликнең җәмәгате дә шунда утырды. Уң якта – әмирләр, сул якта – кунаклар.

Алмыш кулын чәбәкләп алуга, алдына кәбаб – кыздырылган ит китереп куйдылар. Ул аннан өч калҗа кисеп алып авыз иткәч, чираттагысын Сәһсән әр-Рәсибигә сузды.

Шуннан соң гына башкалар ризыкка үрелде.

Гарәпләрдән аермалы буларак, Болгар табынында җыр-бию, күңел ачуларга урын бирелми. Хәлбуки сөҗү атлы әче балны чатагы-чатагы белән китереп кенә торалар. Хәзерендә аның гайрәте тел күәсен генә арттыра. Әнә мәҗлес гөжләпме-гөжли.

Бер җаен китереп, Ибне Фазлан да үзен борчыган бер мәсьәләне кузгатмак итте.

– Падишаһ, – диде ул чираттагы касәне бушатканнан соң, – кичә мин бер мәчеттә булган идем, хотбә догасында имам: «Аллаһеммә әслих әл-мәликә Белеквар мәликә Болгар», – дип тәкрарлады. Бу бит – хата, дөресләккә туры килми.

– Ничек туры килмәсен, – дип Алмыш сәркатипне күз туя күргәндәй тураебрак утырды да, – «Җә, Хода, мәликне, Болгар мәлиге Белекварны, изгелеккә юнәлдер» дигән хотбә ничек хата булсын ди? – диде.

– Әл-Мәлик – Аллаһы Тәгаләнең туксан тугыз исеменнән берсе һәм бик дәрәҗәлесе, – диде Ибне Фазлан, – тимер, җиргә ышкылып, күгәреннән чистарган кебек, без дә Аллаһының гүзәл исемнәрен кабатлап сафланабыз. Мәлик – фәкать бер Хода. Аннан башка затны «Мәлик» дип атау – гөнаһка тиң гамәл.

Алмыш авыз эченнән генә иман китереп:

– Хотбәдә алайса мине ничек атарга соң? – дип сорады.

– Үз исемеңне һәм атаңның исемен телгә алу мәгъкуль санала.

– Мин рухи хуҗам әмирел-мөэминнең исемен алырга телим, – диде Алмыш, – чөнки атаем мөселман түгел иде. Бу мөмкинме?

– Мөмкин, – диде Ибне Фазлан, – хәзрәт Җәгъфәр җине Габдулла дип исем кушсын.

– Хотбәдә ничек телгә алырга тиешләр?

– Аллаһемә әслих габдәкә Җәгъфәр бине Габдулла әмире Болгари мәула әмирел-мөэмин.

– Сиңа, мөэмин туганым, хаталарымны төзәткән өчен игелекле теләкләрем муафәкъ булсын, – дип, кулларын күкрәгенә куйды белекварр, – бик рәхмәтлемен.

Табынга үзенә бер тантана һәм купшылык хозурында кылгандай саргылт озын чәч толымнарын кылтык кына калку күкрәкләренә салган чын болгар кызлары тәлинкәләрен уйната-уйната тары боткасы китерделәр.

Болгар – тары иле. Шуңа күрә тары ризыгы һәрвакыт дастархан түрендә. Әлеге җәһәттән, ул, калышса да, иттән генә калышадыр, мөгаен. Кунакларга хөрмәт йөзеннән бүген тары боткасын бия сөтеннән, кабартып пешергәннәр иде. Әчкелтемрәк исе генә ни тора. Шарты да бар: тәлинкәне ялап кую зарур.

– Каймак ачы, сөт төче, салма бирсәң – камыр, шалкан бирсәң – тамыр, тары боткасы бирсәң, җилегәнә май тулыр, әйдә, боткабыздан авыз итегез, – дип, Белеквар бер кавым ботканы тамагына шудырды.

Ибне Фазланның күңеле исә башкада иде. Баядан бирле патшабикә белән янәшә утырган бер мөлаем ханымга күзе төшеп, каш астыннан гына шул сылукайны күзәтеп утыра. Моны тәхет хуҗасы да сизеп алган икән.

– Бану бикә – дәүләтебезнең бик ихтирамлы, бик абруйлы һәм искиткеч эшлекле әгъзасы, – дип мәгълүмат бирүне кирәк тапты. – «Кала тау», «Кызлар каласы» кальга-бистәләрен төзеде, үзе – менә дигән яугирә. Өч кызын да үз үрнәгендә тәрбияләп үстерде. Бүгенге тантаналы чарабызның иминлеген дә, мисал өчен, төпчеге Хөсникәмал тупланбаш яугирәләре тәэмин итә.

– Күрәм, Болгарда хатын-кызлар, күкәй эчендәге сары кебек икән, абруйлылар, — диде Ибне Фазлан, – хәтта махсус «Кызлар каласы» да бар икән. Мине Бану бикә белән якыннанрак таныштырсаң, бик рәхмәтле булыр идем.

– Мөмкин, бик мөмкин.

– Мөхтәрәм кунагыбыз Ибне Фазланның синең белән танышасы килә, – диде урыныннан торып баскан Бану бикәгә, – берочтан корылмаларыңны күреп китәр.

– Башөсте, падишаһ, – диде бикә сәркатипне күз уңыннан үткәреп, – кунакны кайчан көтәргә боерасың?

– Иртәгә билгелик, бүген ял итсеннәр инде, мәҗлес арыта ул.

Кунаклар мәҗлестән, мондагы йола буенча, ашаудан калган кәрҗин тулы ризыкларын кулларына тотып кайтып киттеләр.

***

Бану бикә «Кызлар каласы» белән танышуны кунакка яшь яугирәләрнең хәрби осталыкларын күрсәтүдән башламак иткән иде дә, тегесе кулын гына селтәде.

– Бикә, сугыш-орыш хәлләренең үз кешеләре бар, ә мин – сәяхәтче, галим, мине шәхсән халыкларның тормыш-көнкүреше, йолалары, гореф-гадәтләре, бер-берләренә, дәхи дә читләргә булган мөнәсәбәте күбрәк кызыксындыра, – диде. – Әлеге сәфәрдән соң хәлифәбезгә шул хакта рисалә язып тапшырырга бурычлымын.

– Ихтыярыгыз, – диде Бану, – алайса, әйтегез, нидән башлыйбыз соң?

– Мөселман кешесенең иң изге урыны – Аллаһ йорты, әйлә намазы да җитә, мәчеткә барыйк, аннан соң күз күрер.

Тәү салынган мәчет күршедә генә иде, шунда керделәр.

Пыяла тәрәзәле зур гына агач мәчет. Якты. Идәненең буеннан-буена яшел төстәге купшы келәм җәелгән. Кешеләр дә шактый күренә.

– Хатын-кызларның үз бүлмәләре бардыр инде, – диде Ибне Фазлан. – Ходай хәерле намаз насыйп итсен.

– Без мәчетне ир-ат – хатын-кызларныкына бүлмибез, – диде бикә.

Билгеле, бу ислам кагыйдәләрен бозу иде, шулай да Ибне Фазлан телен тешләде. Ник дисәң, Болгарда аңа моннан да хәтәррәк сәер «бозу»ларның шаһиты булырга туры килгән иде инде.

Шулай беркөнне Багдадтан килгән тегүче белән ясигъ намазына азан әйтүләрен көтеп, гәпләшеп утырганнар иде. Ниһаять, азан яңгырады. Чыксалар, иртә намаз вакыты җиткән!

Мәэзиннән:

– Кайсы намаз азанын әйттең? – дип соравына тегесе:

– Иртә намаз азанын әйттем, – диде.

– Ә ясигъ намазы кайда?

– Аны ахшам белән бергә укыйбыз, – диде мәэзин.

Баксаң, җәен Болгарда төн бик кыска икән, кояш баерга өлгерми, инде таң беленә башлый. Үзләренчә шуңа җайлашулары, имеш.

Үзләренчә дигәннән, бер авылда ул агач ботагына асып куелган мәеткә тап булды. Хыянәтче токымыннан, күрәсең.

– Исләнеп беткән ич бу, нигә монда тотасыз? – дип белешкән иде, җавабы тагын да сәеррәк яңгырады.

– Хыянәтче түгел ул, бик мактаулы, бик тырыш гыйлем иясе тәкъваи инсан иде, – диде аны озатып йөрүче углан ниндидер үзенә бер горурлык белән, – ә андый изге затларның хакы – Раббебез Аллаһы Тәгалә рухына корбан булу. Аны үз ризалыгы белән асып куйдык. Ул үзе өзелеп төшкәнче асылынып торачак.

Дәвамы бар >

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы,

әнисе

вафат булу сәбәпле, министр урынбасары Энҗе Нияз кызы Нигъмәтҗанованың, гаиләсе, туганнары һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша. Ходай сезгә хәсрәтегезне күтәрә алырдай көч, сабырлык бирсен! Мәрхүмәнең җаны тыныч, урыны җәннәттә булсын!

Буа муниципаль районы Советы һәм Башкарма комитеты, әниләре

ФӘИЗОВА Миңнур Сабир кызы

вафат булу сәбәпле, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Икътисади һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры урынбасары Гайзатуллина Чулпан Нияз кызының, Татарстан Республикасының хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары Нигъмәтҗанова Энҗе Нияз кызының авыр кайгысын уртаклаша.

«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»нан ай саен бер бүләк

1 ЯЗЫЛ!
2022 елның икенче яртыеллыгына «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» газетасына языл

2 КВИТАНЦИЯ КҮЧЕРМӘСЕН БЕЗГӘ ҖИБӘР!
89179270040
info@vatantat.ru
420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт.

3 БҮЛӘК ОТ!
30 майга кадәр газетага язылучылар арасында
ТАНДЫР һәм ӘФГАН КАЗАНЫ
уйнатабыз

6–16 июньгә кадәр газетага ташламалы бәядән язылып була!

П2435
җомга саны
423 сум 48 тиен
гадәти бәясе – ~~488 сум 10 тиен~~

П2409
атнага дүрт тапкыр чыга
942 сум 18 тиен
гадәти бәясе – ~~1099 сум 32 тиен~~

Май ае өчен квитанцияләр 2022 елның 8 июненә кадәр кабул ителә. Бүләк 9 июнь көнне уйнатылачак.

Акция 2022 елның 29 апреленнән башлап 17 июленә хәтле дәвам итә.
Акцияне оештыручы ТР ДБУ «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
Тулырак: vatantat.ru
16+
Реклама

АКЦИЯНЕҢ ИГАНӘЧЕЛӘРЕ

Тандырда пешкән ризык тәмле һәм затлы!
Иң күп сайлау мөмкинлеге – «Тандыр 24» кибетендә.
Сезнең барлык сорауларыгызга җавап бирерләр.

«Тандыр 24», ТР, Казан шәһәре, Закиев урамы, 4 нче й., сул канат, 2 нче кат
тел.: +7-917-919-80-01

Реклама

Корыч казаннар, әфган казаннары, мангал, казаннар өчен мичләр. Безнең кибеттә табигатьтә ризык әзерләү өчен бөтен төр товарлар да бар.
тел.: +7-905-020-00-39
«Мир казанов 116», ТР, Казан шәһәре, Җиңү проспекты, 100 нче й., элмә тактасы – «ЭКОМАРКЕТ»
Реклама



Рәис Габдулла

13 май санында чыккан сканвордның җаваплары
Горизонталь буенча: куб, Они, Мәчетле, оф, Габделфәрт, Сиена, Глеб, Лаки, Зифа, Бальзак, Пеле, фреон, Макаров, әнә, номинал.
Вертикаль буенча: Гугл, яман, лафет, боек, әкәм, комод, бибек, Ани, нәфес, ирән, кич, Ли, лаф, ферзь, Равил, китмән, Изге, Раифа, Брест, акан.

Викторина

Тәкъдим ителгән һәр сорауда җавапларның өч варианттан берсе генә дөрес. Берсен сайлап, белемегезне тикшерегез.

1 **Татарлар турында беренче нәфис фильмның исеме нинди була?**
А) «Сәйәр»;
Б) «Булат Батыр»;
В) «Күктау».

2 **Көнбатыш Рим империясенең таркалуы.**
А) 476 ел;
Б) 632 ел;
В) 962 ел.

3 **Угра буендагы каршы тору ничәнче елда була?**
А) 1395 ел;
Б) 1480 ел;
В) 1500 ел.

4 **1966 елдан Камал театрының баш режиссеры.**
А) Марсель Сәлимҗанов;
Б) Хәлил Әбҗәлилов;
В) Илья Репин.

5 **«Рәнҗеткәннәр сине, рәнҗеткәннәр,**
Бик тә рәхимсез шул бу дөнья.
Көлә-көлә йөгереп барган чакта
Үсеп чыга юлга зур кыя».
Бу шигырь юлларының авторы?
А) Саҗидә Сөләйманова;
Б) Фәнис Яруллин;
В) Илдар Юзеев.

Җаваплар: 1) Б; 2) А; 3) Б; 4) А; 5) Б.

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Индекс П2435
Тираж – 16033 данә
Газетага сертификат бирелде
Заказ 269

РЕДАКЦИЯ һӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульъязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+